ЖИРЛЕ БӘХЕТ

Татарстанда өч һәм аннан күбрәк балалары булган 42624 гаиләгә җирле булган

> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар

> 3, 5



КАНАТЛЫ ТАТАР

Халыкара бию көне уңаеннан Рудольф Нур Нуриевны искә алабыз

> 5

ЖЫРЛЫ ТЕЛ

Татарчаны дүрт айда өйрәнгән Гамзә Нур Налбант башкаларны да Тукай теленә өйрәтергә җыена

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 62 (28835) | Шимбә | 30 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ӘШЛЕ, ШАШЛЫКЛЫ, МИНЕКЕ!

«ВТ» ОЗЫН МАЙ ЯЛЛАРЫ АЛДЫННАН ХАТИРӘЛӘР БАРЛАДЫ

Әле Яңа ел бәйрәмнәрен озатып җибәрдек кенә кебек иде, инде майның хезмәт белән үрелеп бара торган яллары килеп җитте. Кемдер, элеккеге гадәт буенча, әләм күтәреп, шәһәр урамына чыгар, күпләр авылга кайтып, көнен бакчада уздырыр, кичен шашлык кыздырыр. Аерым кешенең генә түгел, һәр буынның үз мае икән бит. Сөйләшә торгач, без шуңа инандык.

«ВТ» архивыннан

Хезмәттәшебез Риман Гыйлемхановның бу җәһәттән хатирәләре бигрәк тә якты. Май ае җиткәндә генә түгел, ара-тирә әйтеп куйгалый ул шул чаклар турында. Бу юлы тулырак, көненә туры китереп сораштык. Шул чакларны сагыну хисләре дә юк түгел икән үзендә.

– Совет чорында яшәгәннәрне кайчак «идеология корбаннары» дип атыйлар. Мин үзебезне «идеология җимешләре», җимешнең татлысы дияр идем. Май бәйрәмендә урам чыгулар безнең заман идеологиясенең матур бер чагылышы булып күңелдә һаман саклана әле. Баш-аягыбыз белән һәрнәрсәгә ышандык дип үк әйтә алмыйм, әммә 1 Май демонстрациясенә олы бәйрәмгә әзерләнгән кебек әзерләнә идек. Студентның «ярлы гардеробы»ннан иң матур киемнәрне кияргә тырыштык. Урам тулы кеше каршында матуррак күренәсе килгәндер инде. Бөтен урамнардан Ирек мәйданына колонналар агыла... Алар туктап торган арада баянга тартча җырлыйбыз, биибез, халык безгә кул чабып тора. Демонстрациягә куып чыгармыйлар иде. Дөрес, стипендияңне искә төшереп, «дусларча» гына әйтеп куюлар булгалады. Әмма мәҗбүрият дигәне юк иде, чөнки халык бәйрәмгә болай да агылды. Ул чакта барлык завод-фабрикалар эшләп торды, Казан урамнарын эшчеләр генә дә тутыра алырлык иде. Хәтерлим: Казандагы демонстрациядә катнашырга якын-тирә районнардан да килгәләр иде. Мондый демонстрацияләр илнең көч-куәтен, халыкларның бердәмлеген күрсәтү өчен оештырылгандыр, әлбәттә. Бу максатны без күңел белән сиздек. Шундый илдә яшәвебезгә шатланганбыздыр да. Юкса күңел иң яхшы хисләрдән ташымас иде, – дип хатирәләрен бирелде ул бу юлы да.

Зәй районының Югары Шепкә авылында яшәүче Рәфинә Мостафина өчен дә май башы үткәндәге якты истәлекләре белән кадерле.

– Май бәйрәмнәрен кечкенәдән үк белеп үстек, көтеп алдык. «Тынычлык! Хезмәт! Май!» дип язылган тәбрикләмәләр сатыла иде. Без бер-беребезне шуларны биреп, котлашкан хәтердә. Башка авылларга почта аша да юллый идек. Бәйрәмне ел саен түгәрәк. Бакча башына чыгып, «Завтрак туриста» консервасын ашап, бәрәңге тәгәрәтеп, чәй кайнатып, уйнап кайта торган булдык. Үзебезнең урам балалары белән мәш килдек, – дип сөйләде ул. – Үсә төшкәч, әниләр бәйрәм җиткәнче көтеп торды инде. Бәрәңге чыгарасы, сарык йонын аласы бар бит. Авыл җирендә күмәк эшләрне өмә белән эшли идек. Хәзер без дә балаларыбызның кайтканын көтеп торабыз. Бәйрәмгә кайтсалар, бакча казырлар, яшелчә утыртык идек, дип. Олыгайгач та бәйрәм бәйрәм булып кала инде ул. Эшләр бетүгә шашлыкын да әзерлибез.

Мал табибы Илдус Хатыйповның май яллары шахси бәйрәмнәр белән үтеп китә икән.

– Демонстрацияләргә йөргән вакытлар миңа эләкмәде, картайтма, – дип шаяртты ул. – 90 нчы елларда май бәйрәмендә без кросс чаба идек. Казан буенча, Кремль урамыннан... Яшь чак шулай узылган. Гаиләбез өчен шахси бәйрәмнәр белән дә истәлекле бу ай. 1 майда – әтинең туган көне, 9 майда – олы кызымныкы. Май бәйрәмнәре туган көн шаукымында үтә. Эш дигәндә, безгә аны Май бәйрәме булмаса да эшлисе. Шашлык кыздыру гадәте дигәннән, аны хәзер май ялларын көтмичә дә кыздырып ашарга була. Ит алырлык акчасы һәм күмерең булсын.

Казаннан Фидания Лерон гаиләсендә май бәйрәмнәренә карата матур традицияләре бар.

– Май ялларында авылга әнигә, әтигә кайтабыз. Студент елларыннан бирле саклап калган гадәт бу. Әле дә дәвам итә, шөкер. Кукмара районының Октябрино авылында яшәүче 85 яшьлек минем әнием дә, Ләбибнең Мөслим районының Түреш авылында көн күрүче 87 яшьлек әтисе дә безне көтеп тора. Май ялларында бакчабызда эшләргә дә өлгерербез дип уйлыйм. Язын кайда да эш инде, – диде ул.

Ялда эшләп, эшкә ял итәргә бара торган чак. «Татарстан» телерадиокомпаниясе алып баручысы Айзилә Батырханова майның озын ялларын әнә шулай тасвирлый.

– Минем һәм гаиләм өчен май яллары чын мәгънәсендә хезмәт бәйрәме ул. Гадәттә, 1 майда без өй юарга керешәбез. Йортыбыз зур булгач, бер көндә генә башкарып чыгып булмый, әлбәттә. Хуш ис чыгарып өй юганда әйтерсең лә кыш буе җыелган тискәре энергиядән котыласың, – дип сөйләде ул. – Әни бу көнгә туры китереп бик тәмле итеп суган сумсасы пешерә. Шашлыкка урын калмый да. Май ялларында өйдә ныклап эшләп, төп эшкә исә ял итәргә барырга гына кала.

Журналист Ләйсән Хәкимуллина, яңа буын вәкиле буларак, май бәйрәмнәренә артык әһәмият һәм игътибар бирмим, ди.

– Иманым камил: минем яшьтәгеләрнең күбесе «Тынычлык! Хезмәт! Май!» дигән лозунгның асылын, кайдан, ник килеп чыкканын, нәрсә аңлатканын да белми. Бу көннәрне минем беркайчан да рәттән өчәр көн шашлык кыздырып, ял итеп уздырганым булмады, – дип сөйләде хезмәттәшебез. – Шушы өч көндә, бөтен гаилә бергә булган вакытта, өйдәге, бакчадагы бик күп эшләрне башкарып калырга тырышабыз. Авылда торабыз бит, «нишлим икән?» дип аптырап йөрисе юк. Шуның өстенә, эшкә дә чыгып кермичә булмас. Мин бит – журналист, ә журналистлар барлык халык ял итеп, күңел ачып йөргән вакытта гадәттәгечә эшли.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Теманың дәвамы 6 нчы биттә >

> Яз һәм Хезмәт бәйрәме беренче мәртәбә 1890 елда Варшавада билгеләп үтелә. Аннан ул Санкт-Петербургта да оештырыла. 1897 елда исә бәйрәм чарасы тәүге тапкыр сәяси төсмер ала. Бу көнне митинг-демонстрацияләр оештырыла башлый.
> Без бәйрәм Беренче Май сәяси түгел, ә, бәлки, гаилә, җыелышу бәйрәменә әверелде. 2001 елда Беренче Май дәүләт бәйрәме статусын алды һәм ял көне дип игълан ителде.

БӘЙРӘМ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИННЕХАНОВның Ураза бәйрәме уңаеннан ТӘБРИКЛӘВЕ

Кадерле татарстанлылар!

Хөрмәтле ватандашлар!

Сезне рамазан ае тәмамлану һәм Гайдел-фитр – Ураза гаете уңаеннан чын йөрәктән котлыйм.

Мөкатдәс бу бәйрәмдә һәр мөэмин чиксез нигъмәтләре һәм Кадер кичәсендә индерелгән Коръән Кәрим өчен рәхимле Аллаһы Тәгаләгә мәдхия-мактаулары юллый, гыйбадәт кыла. Ураза вакытында кешегә ихлас догаларының, тән һәм җан сафлыгы турында кайгыртуының, хәерле ниятләренең, игелекле эшләренең әҗер-савабы – уразаны тоткан кешеләргә дә, Аллаһының мәрхәмәте һәм ярлыкавы насыйп була.

Ураза гаетендә Татарстан мөселманнары, Мәккә тарафына уй-карашларын юнәлтеп, миллионлаган дин кардәшләребез белән бергәләп Аллаһтан кешелеккә тынычлык һәм иминлек бирүен сорый. Хәзерге катлаулы, һәрберебездән сабырлык һәм олпатлык белән гамәл кылу, милләтара, динара хезмәттәшлекне ныгытуда, башка халыкларның диненә, мәдәниятенә һәм теленә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүдә шәхсән катнашу таләп ителә торган заманда моның мөһимлеге аеруча ачык аңлашыла.

Татарстанның һәм бөтен Россиянең мөселман өммәте өчен бу ел бик истәлекле: Идел буе Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүенә 1100 ел тула. Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның боерыгы нигезендә дәүләт дәрәҗәсендә билгеләп үтелачәк бу олуг бәйрәмнең Татарстан өчен дә, барлык Россия өчен дә әһәмияте гаять зур. Бу уңайдан уздырылачак күпсанлы чаралар мәңгелек рухи хәзинәләрнең тәэсире тагын да артуга, күпмилләтле халкыбызның тагын да берләшүенә, тарихи гаделлек урнашуга бәрәкәтле этәргеч бирер дип уйлыйм.

Ураза гаете ул – игелекле гамәлләр һәм миһербанлылык тантанасы. Рамазан аенда җәмәгать ифтарлары, мәдәни-мәгърифәти, хәйрия кичәләре һәм балалар бәйрәмнәре уздыру Татарстанда күркәм гадәткә әйләнде. Республика мөселманнары мохтаҗлар һәм бүгенге көндә зур бәлагә тарган, йорт-җирләрен ташлап, күченеп килергә мәҗбүр булган кешеләр белән йөрәк җылысын һәм бәйрәм ризыкларын юмартларча бүлешер дип ышанам.

Бу изге бәйрәм көннәрендә Раббыбыз күңелләребезне шәфкать-мәрхәмәт, мәхәббәт нурына күмсен, иманыбызны ныгытсын! Һәркемгә бәхет, тынычлык, сәламәтлек, иминлек телим!

Бәйрәмнәрдә түлисе юк

Май бәйрәмнәрендә «Пушкин картасы» иясләренә махсус чаралар әзерләнгән Татарстан Россия күләмендә узды-рыла торган «Пушкин картасы» белән май бәйрәмнәре» акциясендә катнаша. Бу хакта Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова хәбәр итте.

«Татарстанда яшьләрнең 70 проценты якыны «Пушкин картасы»н алган. Бу – Россия төбәкләре арасында иң яхшы күрсәткечләрнең берсе. Ә сатылган билетлар саны буенча Мәскәүдән генә калышабыз», – диде Юлия Әдһәмова. «Пушкин картасы» белән май бәйрәмнәре программасына кертелгән чаралар 30 апрельдән 10 майга кадәр узачак. Бу көннәрдә театраль премьералар, концертлар, күргәзмәләр оештырылачак, Татарстанның музей-тыюлыкларына экскурсияләргә барырга мөмкин. Республиканың күп кенә музейларында балалар һәм өлкәннәр өчен квестлар оештырылачак. Мәдәният министрлыгы тәкъдим иткән исемлектән күренгәнчә, Татарстан буенча 160ка якын чара узачак.

Ветераннарга – аерым мөнәсәбәт

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина журналистлар белән очрашу вакытында республикада Җиңү көне нинек узачагы турында сөйләде.

Бәйрәм чараларында катнашучылар өчен битлек кию режимын сакларга киңәш ителә. «Оештыручылар ветераннарга битлек таратачак, су белән тәэмин итәчәк. Сәламәтлек саклау министрлыгы белән ветераннарны бәйрәм чараларына 7 көн кала күзәтү мәсьәләсен хәл итәбез», – диде Любовь Авдонина.

Бәйрәмдә катнашучыларның коронавируска каршы прививкалы яки соңгы ярты елда коронавирус белән чирләве турында расланган белешмәле булуы кирәк.

Ә «Үлемсез полк» йөреше вакытында социаль дистанцияне сакларга кирәк булачак.

COVID-19

Иркенәймәдекме?

Роспотребнадзор белгечләре шулай дип борчыла һәм коронавирусның яңа «дулкын»ын фаразлый. Вазгыять нинди булыр?

Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков әйтүенчә, чирләүчеләр саның май азагына артуы ихтимал. Хәзер медицина фәне белгечләренең игътибары да вазгыять кискенләшкән чит илләргә юнәлгән.

– Азия дәүләтләренә карыйбыз. Сер түгел бит: бер ил авырый башласа, аның артыннан башкасы да чирли. Тәҗрибә шуны күрсәтә. Вирусның яңа төре турында мәгълүмат бик аз. Яңа штаммнан үлү очраклары аз, әммә авыручылар күп, – диде белгеч. – Яңа «дулкын» була калса, сәламәтлек саклау тармагы аны әзер килеш каршы алачак. Әммә күп нәрсә халыктан да тора.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Владимир Жаворонков бу җәһәттән вакцинация һәм кабат вакцина ясау турында искә төшерде. Соңгысына кешеләргә бик ашкынып тормыйлар. «Ревакцинацияне 297639 мең кеше узды. Республикада 741389 мең кеше ревакцинация узарга тиеш», – диде ул, ярты ел элек прививка кадаткан кешеләрне сәламәтлеге турында онытмаска өндәп.

Киләчәкне фаразлаганчы, хәзерге вазгыятькә күз салу зыян итмәс. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина сүзләренчә, хәзерге вакытта республикада коронавирус чире таралу коэффициенты 0,9 процентны тәшкил итә. Соңгы тәүлектә чир йоктырган 218 кеше ачыкланган.

Моңа карап коронавируслы сырхауларны дәвалау өчен булдырылган ятакларның саны кимегән. Республикада алар – 580. Буш ятаклар бар әле, диләр.

– 16 вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитале ачык кала бирә. Бу сан куркытмасын иде. Республикага бер госпиталь калдыру максаты тормый. 16сы да вакытында медицина ярдәмен алырга мөмкинлек бирә, – диде Владимир Жаворонков бу җәһәттән.

Инде барысын да куптәннән кызыксындырган сорауга күчик. Татарстанда әле дә битлек кию режимы саклана. Авыручылар саны кимү дә, вазгыять тотрыкланы да бу кагыйдәдән баш тартырга мөмкинлек бирмиме?

– Битлек кию режимы Россиянең баш санитар табибы карарында беркетелгән. Аны бетеру карары да федераль дәрәҗәдәге карарда билгеләнәчәк. Андый карар булса, ул гамәлгә ашырылачак та. Хәзергә исә бу мәсьәләгә бәйле берниди дә үзгәреш юк, – диде Любовь Авдонина. – Күп кенә кешеләрнең бу кагыйдәгә битараф булуы кызганыч, әлбәттә. Иркенәйдек. Чир кабат баш күтәрергә мөмкин. Битлек режимы үтәргә кирәк, бигрәк тә җәмәгать урыннарында.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Айрат ФӘРРАХОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Соңгы 10 елда медицина җиһазларының зур өлеше Россиядә җитештерелә башлады. Әйтик, моңарчы без ясамаган томографларны. Әммә без беркемгә дә бәйле түгел дип, күкрәк киерә алмыйбыз әле. Азия базарлары – Кытай, Һиндстан иң заманча җиһазларны тәкъдим итә. Шулай булгач, безнең проблемалар булыр дип уйлыйм.

(«Реальное время» интернет басмасына әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ХЕЗМӘТ ХАКЫ

Татарстанстат оешмасы мәгълүматларына карарганда, 2022 елның гыйнвар – февраль айларында республикадагы оешма һәм предприятиеләрдә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 46169,5 сумны тәшкил иткән.

ИҢ КҮП ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТҮЛӘНГӘН ТАРМАКЛАР

Мәгълүмат һәм элемтә	72685
Казылма байлыклар чыгару	70179
Финанс һәм иминиятләштерү	69994
Фән һәм техника	59453
Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү	59449

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Акрын килгән хаста

Салкын тию, томау төшү кебек чирләр тиз генә килеп чыга да, без искә килгәнче, бетеп тә куя. Авыр зәхмәт, мәрхүм әбием әйтмешли, ашыкмыйча, акрынлап килә, ләкин берәгәйле була. Соңгы вакыйгаларга, алар китергән санкция-чикләүләргә бәйле икътисад кризисы да безне әлегә бугаздан алмады. Ул кабаланмый, кыбырсымый, әмма килә. Буар елан сыман акрынлап, тик җиренә җиткереп кысарга, күрәмсең, исәбе. Моны ике атна чамасы элек Татарстан Президенты да искәртте: «Без әле инерция буенча яхшы яшибез. Тик хәлләр катлауланачак».

Тарихта тиңе булмаган санкция-чикләүләр дисәләр дә, аларның ил икътисадына тәэсире әлегә бәяләр артуда гына сизелә. Элек җыелган түл тук тормышны әлегә ярыйсы җайлый. Кибетләрдә ризык җитәрлек, куллану товарлары белән дә проблема туганы күренми. Күпмегә кадәр шулай барачак? Кистереп әйтү авыр. Пессимистлар яңадан ярты, бер елдан продукция карточкалары, бартер, дефицит кайтачагын, хәтта ки завмаг, база директоры кебек затларның, совет заманындагы кебек, күкрәк киереп йөрүен фаразлый. Бәлки алай ук булмас та, әмма пессимист дисәк тә, аларның, кем әйтмешли, мәгълүмат җыйган оптимист икәнен дә онытмасак иде.

Безне Советлар Союзы 2.0, ягъни юкка чыккан илнең икенче номерлы версиясе көтә, диючеләр дә бар. Андыйлар яңадан Госплан, Госснаб ише институтлар туачагына, базар мөнәсәбәтләренең тараюы, хәтта бетүенә ишарәли. Союзга кайту димәктә дөреслек күпмедер бар, әлбәттә. Ул барыннан да бигрәк аерымланып яшәүгә, изоляциягә кайтып кала. Дөрес, бүген дөньясы да башка. СССР 2.0 диюдә дөрес түгеллек исә шунда – Советлар Союзы индустриаль, ягъни үзенең күптармаклы икътисады, җитештерүе булган ил иде. Сыйфатлымы, сыйфатсызмы, «сами с усами» дип, без барысын да әвәләп, ясап тордык. Дистә еллар буе шулай көн күрдек. Бүгенге Россия исә, сатып алу очсызгарак төшә дип, кадак та ясамый.

Ә бит нефть долларлары елга булып аккан 2000 нче еллар башында ук кергән акчаның бер өлешен яңа индустриализациягә тота ала идек. Ул заманнарда Көнбатыш белән дә аралар җылы иде. 30 нчы еллардагы Сталин индустриализациясе чорындагы кебек, бар булган җиһаз, станок, технологик линияләрне, хәтта тулы заводларны да алар рәхәтләнеп сата, ә без ала ала идек. Тик ни хикмәт, без ул чорда демократия дулаган еллардан калган икътисади кыйбла – барысын да базар үзе көйли, һәммәсен үз урынына куя дигән тәгълимат белән яшәдек. Нәрсә җитештерергә, нәрсәне сатып алырга, дөньяга ни чыгарырга – автомат рәвештә базар хәл итә, дигән караш белән. Андый карашны дөрес түгел дип тә әйтеп булмый. Сәяси вазгыять куермаганда, башка илләр белән аркан тартышу ише матавык, кемнәргәдер хас мин-минлек, амбицияләр булмаганда ул принцип эшли. Бозылышмаганда, икътисадны сәясәттән өстен күргәндә, базар – чыннан да, барысын да җайларга сәләтле механизм, ул – рациональ. Әмма сәясәт белән мавыкканда базар кире эффект биреп куярга, тәртәгә тибәргә дә мөмкин. Бүгенге шартларда безгә сыңар станок, сыңар технология дә сатмау белән куркыталар. Хәзер ничек тә әнә шул хәлдән чыгу юлын табарга туры киләчәк.

Бүген монопсония дигән төшенчә модага кереп килә. Ул сатып алучы, кулланучы монополиясен, аның кубызына биюне аңлата. Көнбатыш алмаган яисә көннән-көн азрак алган нефтьне, мәсәлән, без бүген 30–40 процентлы дисконт (ташлама) белән Һиндстанга сатарга мәҗбүр. Кытай да Көнбатыш белән Россия арасындагы конфликттан бары шул рәвешле файдаланачак. Бу хәлләр, үз чиратында, чимал сатудан кергән акчаның кимүен аңлата. Ә инде чималның тапканын да сата алмыйбыз икән, чыгаруны чикләргә, скважиналарны туктату, эшчеләрне, аз дигәндә, ялга җибәрү, күп дигәндә кыскарту куркынычы килеп туа.

Кытай димәктән. Күк асты иленең АКШ белән мөнәсәбәтләре киеренке, ул бүгенге шартларда тотар да Россия ягына авышыр, авыр вакытта безгә ярдәмгә килер, дип уйлау – беркатлылык. Кытай үзенең 3 триллионга җиткән валюта резервларын долларда тота. Аларның Европа Берлеге белән дә товар әйләнеше безнең ил белән булган әйләнешкә караганда күп тапкыр зуррак. Көнбатыш аларга яңадан-яңа технологияләр сатып тора, инвестицияләр сала. Сары кавем Көнбатыш белән булган багланышларын саклаячак. Шуңа күрә АКШ, Европа ягына кул селтәп, Көнчыгышка борылабыз да рәхәтләнеп яшәп китәбез, диюдә дә хакыйкать аз. Кытай, Һиндстан, Иран, Төркия белән сәүдә, алыш-биреш сакланачак, күпмедер артачак, тик ниндидер концептуаль борылыш турында сүз куерту урынсыз.

Европа Берлеге бүген чикләүләрнең 6 нчы пакетын хәстәрләп ята. Ул икенчел санкцияләргә багышланачак, дип язалар. Башкача әйткәндә, Көнбатыш үзе бездән импортлаган җир маен айдан-айга киметү өстенә, Россиядән нефть сатып алучы башка дәүләтләргә карата да чикләүләр системасы булдырачак. Аларны да тыярга тырышачак. Идеалда АКШ һәм Европа бездән «кара алтын»ны беркем дә, хәтта дисконт белән дә сатып алмасын дип тырышачак. Аларга Россияне валютасыз калдыру, аның читтән үзенә кирәкне бөтенләй сатып ала алмавы кирәк. Тормышка ашыра алганда моны безне «бикләү»нең ахыр актларыннан берсе диярге мөмкин…

Ләкин килеп туган вазгыятьтә, бернәрсәгә дә карамастан, Европа, АКШ, гомумән, Көнбатыш дөньясы белән чагыштырганда, россияле кавемнең һичкем тартып ала алмаган бер өстенлеге бар – ул түзем һәм талымсыз. Шул сыйфат безне теләсә нинди тетрәнүләр аша исән чыгарырга сәләтле. Пошаманга төшмик.



vk.com

БЕР ЭШТӘ

Хакимият вәкилләре һәм гражданлык җәмгыяте иңгә-иң торып эшләргә тиеш. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанда эшчәнлек алып баручы иҗтимагый оешмалар (волонтерлык хәрәкәтләре, иҗат берлекләре, медицина һәм мәгариф, мәдәният, тормышта авыр хәлләрдә калган кешеләргә социаль ярдәм өлкәсендә проектларны тормышка ашыручы оешмалар) җитәкчеләре белән очрашуда шулай диде.

Татарстанда барлыгы 6 меңнән артыграк НКО һәм 100дән артыграк иҗат берлеге, тармак берләшмәсе теркәлгән. Республика иҗтимагый оешмалар саны буенча Идел буе федераль округында беренче урында.

– Яңа кыенлыклар килеп чыккач, дәүләт кайвакыт тиз генә тиешле чара күрә дә алмаска мөмкин, – диде парламент башлыгы. – Мондый шартларда нәкъ менә иҗтимагый оешмалар, волонтерлар алгы планга чыгып, ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә булыша.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, соңгы вакытларда (башлыча коронавирус пандемиясенә бәйле рәвештә) иҗтимагый оешмаларның социаль активлыгы артты, алар җирле һәм дәүләт әһәмиятендәге мөһим бурычларны хәл кылуга ешрак алына башлады.

– Илебездә җаваплы, бердәм гражданлык җәмгыятенең булдырылуы турында сөйли бу, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – Бүген бөтен җәмгыятьне бер йодрыкка туплап бердәмлек күрсәтү кайчандагыга караганда да мөһим. Илдә һәм республикада тотрыклы вазгыять булдыру, Россия халыкларының бердәмлеген ныгыту максатында, дәүләт хакимияте органнары гражданлык җәмгыяте белән иңгә-иң торып эшләргә тиеш.

Дәүләт Советы Рәисе шулай ук иҗтимагый оешмаларны илкүләм проектларны тормышка ашыруда актив катнашырга чакырды. Узган елда бу эшкә нибары 5 НКО җәлеп ителгән. Хәзерге вакытта илкүләм проектларны гамәлгә ашыруда 11 коммерциясез оешма катнаша.

Иҗтимагый оешмалар вәкилләре төрле яклап ярдәме өчен республика җитәкчелегенә рәхмәт белдереп, социаль әһәмиятле проблемаларны тормышка ашыру буенча муниципаль хакимият вәкилләре белән хезмәттәшлекне көчәйтү тәкъдимен җиткерде. Моннан тыш алар законнар иҗат итү өлкәсендә парламент комитетлары, экспертлар советлары белән актив төстә берлектә эшләргә әзер булуларын белдерде.

«Закон чыгаручылар белән тәүге шундый очрашу әле бу. Аның традициягә әйләнәсенә ышанам, – диде Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева. – Иң мөһиме – коммерциясез оешмалар белән хакимият арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен урнаштыру омтылышы бар».

Җырлап яшиләр

Казанда ветераннар арасында үзешчән башкаручыларның җиденче «Балкыш» республика фестиваленең гала-концерты узды. Быел әлеге фестиваль Татарстан ветераннар (пенсионерлар) оешмасы оешуга 35 ел тулуга багышланган иде. Шулай ук быел «Балкыш» оешканга да 10 ел тулды.

Фестивальдә катнашучылар белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да очрашты. «Фестиваль хәрәкәте дистә ел эчендә зур иҗади җыенга, республиканың «визит карточкасы»на әйләнде, – диде парламент башлыгы. – Ә иң мөһиме – мондый чаралар үткәрүдә сез үзегез башлап йөрисез».

Фәрит Мөхәммәтшин өлкән буынны Татарстанның «алтын фонды» дип атады.

– Хәрәкәттә булу, күңелегез белән һәрвакыт яшь булып калу, һәрдаим иҗатка омтылу, республика халыкларының мәдәнияте һәм традицияләрен саклауга үзегездән эчкерсез өлеш кертү, яшьләргә тәҗрибә тапшыру теләге зур хөрмәт уята һәм барлык хакимият баскычларында хуплау таба, – дип билгеләп үтте ул. – Әлеге концертны бәйрәм бүләге итеп кабул итегез!

Дәүләт Советы Рәисе бүген бердәмлекнең кирәклеген дә искә төшерде.

tatarstan.ru

– Безнең республика, кыенлыклар килеп туганда, һәрвакыт бердәмлеге белән аерылып тора, – диде ул. – Татарстан мәҗбүри күченеп килгән 1,5 мең чамасы кешене кабул итте. Мондый вакытта сабырлык һәм бердәмлекне саклау, игелеклелек һәм мохтаҗларга ярдәм кулы сузу бик мөһим. Бу мәсьәләдә өлкән буынның роле гаять зур. Сезнең зирәклек, рухи көч һәм ныклыгыгыз, дустанә ярдәмегез һәм шәхси үрнәгегез яшьләргә теләсә нинди кыенлыкларны җиңәргә, илне яңа үсеш баскычларына чыгарырга ярдәм итәчәк.

АГАЧ – ҖИМЕШЕ, КЕШЕ – ЭШЕ БЕЛӘН

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Яз һәм Хезмәт бәйрәме уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне чын күңелдән Яз һәм Хезмәт бәйрәме белән котлыйм!

Майның беренче көне аеруча рухи күтәренкелек бирә, яшәү һәм эшләү теләге уята. Халкыбызның инде менә дистәләгән еллар дәвамында яраткан бәйрәменең үзгәрмәс асылы – Ватаныбыз хакына намуслы эшләүче Хезмәт Кешесен, чын Ватанпәрвәрне ихтирам итү. Ул, республиканың һәм илнең алгарышлы социаль-икътисади үсешен тәэмин итеп, үз белемнәрен һәм тормыш тәҗрибәсен үсеп килүче буыннарга тапшыра.

Безнең халыкта «Агач – җимеше белән, кеше – эше белән» дигән мәкаль бар. Татарстан үзенең эш сөючән һәм талантлы халкы белән дан тота. Бүген безгә үзгәрешләр һәм күп кенә сынаулар чорында яшәргә туры килә. Әмма дәвам итә торган пандемия, гаять авыр халыкара вазгыять, җәмгыятьтә кризис тудыру, Россиянең дәүләт нигезләрен какшату максаты белән моңарчы күрелмәгән санкция басымы шартларында без үз эшебезнең остасы булып калырга, бердәм һәм сабыр булырга тиеш. Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин һәм илебез Хөкүмәте тарафыннан икътисадның тотрыклылыгын саклап калу, гражданнарны социаль яклау дәрәҗәсен арттыру буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Кризиска каршы штаблар эшли, Татарстанның дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимияте органнары тарафыннан тотрыклылыкны тәэмин итү буенча гамәли адымнар ясала. Бүген республика барлык сынауларга да каршы тора, иң четерекле мәсьәләләрне дә хәл итә алуын тагын бер кат раслый.

Кадерле дуслар! Һичшиксез, күпмилләтле дәүләтебез кичергән бүгенге вазгыять вакытлыча күренеш кенә. Тарихыбызда авыррак чорлар да булды. Без һәрвакыт ышаныч һәм ныклык белән бу авырлыкларны җиңеп чыктык. Ышанам ки, алга таба да шулай булыр. Бәйрәм көнендә сезгә сәламәтлек, бәхет, тынычлык, ышанычлы киләчәк һәм эшегездә уңышлар телим. Бердәм булыйк, шул чакта иң кыю ниятләребез һәм хыялларыбыз һичшиксез тормышка ашачак!

ҖИРЛЕ БӘХЕТ

Сабый үз җире белән туа. Татарстан Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматларына караганда, өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә 42624 җир участогы бирелгән. Кадастр учетына 46236 җир кишәрлеге куелган. Аларның 7147се – Казанга, 3405е Чаллыга туры килә.

Быелның 26 апреленә булган мәгълүматлар буенча, күпбалалы гаиләләрдән кабул ителгән гаризалар арасыннан 67832сен исемлеккә кертергә карар кылынган. Әлеге гаиләләрнең 17099ы Казаннан булса, 8744е – Чаллыдан.

Азнакай районының Мәнәвез авылында яшәүче Гөлназ һәм Эльнар Исламовлар да, быел күпбалалы гаилә буларак, җир участогы алу бәхетенә ирешкән.

– Без бик канәгать, чөнки җирне шәһәргә якын булган бистәдән бирделәр, – дип куанычы белән уртаклашты Гөлназ. – Өченче балабыз 2018 елда туды. Җир кишәрлеге алу өчен документларны исә бер елдан соң тапшырдык. Шуңа күрә безгә озак көтәргә туры килде, дип әйтеп булмый. Быел бездән кала, шактый гаилә участоклы булды дип беләм. Киләчәктә биредә йорт салырбыз дигән уебыз бар.

Исламовлар моңа кадәр дә республика программаларыннан уңышлы файдаланган булган. Биш ел элек алар программа буенча йорт салып кергәннәр.

– Ул вакытта безгә, яшь белгеч буларак, 1 миллион сумнан артык акча бирелгән иде. Аңа авылда йорт салып кердек. Программа шарты буенча, минем исемдә җир булуы һәм авылда эшләвебез кирәк иде. Ул чагында да бернинди проблемалар булмады. Документларны да тиз арада җыеп тапшырдык, ә акча алты-җиде ай эчендә күчте, – ди Гөлназ Исламова.

Яңа гына алган җир кишәрлекләре шәһәргә якын булса да, гаилә авылдан китәргә җыенмый.

– Без авылны яратабыз. Әлеге вакытта яши торган җиребез миңа мирас буларак әбидән күчте. Гомумән, авыл белән мине нәселем бәйли. 100 ел элек Мәнәвезгә нигез салучы 40 гаилә арасында әти ягыннан әбинең әтисе Шиһаб та бар. Ул авылның беренче мулласы булган. Шуңа күрә минем төп бурычым – нигезне саклап яшәү. Балаларга да туган җир, нигез кадерен сеңдереп үстерергә тырышабыз. Өч ул тәрбиялибез. Киләчәктә аларның берсе нәсел нигезен саклаучы булуына өметләнәбез, – ди Гөлназ.

Җир кишәрлеге алучылар еш кына участокларда кирәкле инфраструктура – яктылык, су, газ, юллар һәм социаль объектлар белән тәэмин ителеш булмаудан зарлана. Ләкин без аралашкан кешеләр барысы да бик канәгать булуларын әйтте.

Әлки районының Каргалы авылында яшәүче Гүзәл һәм Ирек Сәлахиевлар гаиләсендә дә өч малай тәрбияләнә. Төпчекләре 2017 елда туган, ә җирне алар ике елдан соң алганнар.

– Без җир алу мәшәкатенең нәрсә икәнен дә белмәдек. Барысын да авыл советы эшләп бирде, – ди гаилә башлыгы. – Җирне авылдан ерак булмаган урыннан бирделәр. Күл, агачлык янындагы матур гына урын ул. Мин анда умартачылык белән шөгыльләнә башладым. Аңа кадәр умарталарны бакчада тота идем. Хәзер рәхәтләнеп эшләр өчен барлык шартлар да бар. Авылдашларыма да комачауламый. Зур булмаган бер бина да салып куйдык. Анда умартачылык өчен кирәк-яраклар саклана. Бал аерткач, утырып чәй эчә торган урыныбыз ул.

Ирек Сәлахиев әйтүенчә, авылда берничә гаилә җир алу бәхетенә ирешкән.

– Җирне район үзәгеннән бирмәсләр микән, дигән уем да бар иде. Ләкин умарталык өчен монысы тагын да уңышлырак килеп чыкты. Без бик сөенәбез, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

САНАГАН БЕЛМИ, УКЫТКАН БЕЛӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Информатика дәресләрендә компьютер куллану буенча исемлектә Татарстан нибары 44 урынны алган. IT-башкала булырга хыялланган республика өчен бу бер дә күңелле хәл түгел. Башка юнәлешләрдә дә «2ле» алучыларыбыз күбрәк икән. Сәбәбен Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләреннән сорадык. Алар фикеренчә, әлеге күрсәткечләр белән генә мәгариф системасына бәя биреп булмый.

Узган ел Рособрнадзорның белем сыйфаты буенча гомуми рейтингында Татарстан 22 нче урында иде. Быел исә һәр юнәлеш буенча аерым нәтиҗәләр чыгарганнар. Республика укуда артта калган укучылар саны буенча – 41 нче урында. Шунысы гаҗәп: Идел буе федераль округында иң начар күрсәткеч бу. Шул ук вакытта имтиханнарның гадел үтүе буенча да 45 нче урында саналабыз икән.

– Чыннан да, Рособрнадзор һәм Белем сыйфатын бәяләү буенча федераль институт кайбер критерийлар буенча нәтиҗәләр игълан итте. Әмма бу абсолют күрсәткечләр түгел һәм моңа карап кына Татарстан мәгариф системасына тулысынча бәя биреп булмый. Мәсәлән, 2021 елда имтихан кампаниясе нәтиҗәләре буенча республика беренче тапкыр беренче унлыкка (9 урын) керде. Бөтенроссия олимпиадаларында җиңүчеләр һәм призерлар саны буенча да ил күләмендә 3 нче урынны саклап калдык. Республика укытучылары һәм тәрбиячеләре ел саен иң яхшылар бишлегенә керә. 12 күрсәткечнең җидесе буенча республика югары баллар алып, яшел зонада. Бер генә күрсәткеч буенча да Татарстан кызыл зонага эләкмәде. Шул ук вакытта, белем сыйфаты буенча барлык күрсәткечләрне дә яхшырту өчен резервлар бар, – ди Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү бүлеге җитәкчесе Татьяна Алексеева.

Компьютердан файдалану күрсәткече төбәкләрдә информатикадан имтихан сайлау күрсәткечен (хәзер укучылар имтиханны компьютерда тапшыра) дә үз эченә ала. Әлеге сынауны Татарстанда мәктәпләрнең 55,5 проценты сайлый. Мәскәү, Санкт-Петербург, Мәскәү өлкәсе иң алдынгылар дип табылган. Исемлек ахырында – Карачай-Черкесс, Ингушетия, Дагыстан республикалары. Әйтик, Дагыстан укучыларының 23,5 проценты гына информатикадан имтихан тапшырган.

Арчадагы 6 нчы мәктәп директорының мәгълүмати технологияләр буенча урынбасары, информатика укытучысы Илшат Фәйзуллин әлеге фәннән күрсәткечләрнең түбән булуының берничә сәбәбен атады.

– Информатикадан имтиханны алсак, берничә сәбәпне билгеләргә була. Беренчедән, информатиканы иң көчсез балалар сайлый. Ни өчен дигәндә, әлеге фәннән чик балл түбән. Алты балл җыйсаң да җитә. Башка фәннәрдән бу бермә-бер артык. Икенчедән, район мәктәпләрендә программалаштыруны белгән информатика укытучылары бик аз. Математика, физика укытучыларының барысы да яхшы информатик була ала дигән сүз түгел. Аларны аерым әзерләргә кирәк, – ди Илшат Фәйзуллин. – Яхшы «айтишник»лар бизнеска китә. Безнең мәктәп укучысы Даниил Щепкин «Андроид»та төрле кушымталар программасын өйрәнеп, Россия чемпионы булды. Аны шунда ук бездән Казандагы элемтә техникумына алып киттеләр. Бүген ул студент булуына карамастан, лабораториядә үзе студентларны өйрәтеп, акча эшли. Район башлыгы әлеге егетнең аннан да күбрәк хезмәт хакы алуын әйтте.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланың беренче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) региональ әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмати тәэмин итү, шул исәптән юл фондлары акчаларын булдыруны һәм алардан файдалануны тикшереп тору системасы ярдәмендә;»;

3) 13 статьяның 12 пунктында «, шул исәптән юл фондлары акчаларын булдыруны һәм алардан файдалануны тикшереп тору системасы ярдәмендә» сүзләрен өстәргә;

4) 13[1] статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мондый очракта тикшереп тору (күзәтчелек итү) чаралары актларын төзү һәм аларның нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләр бирү күрсәтелгән дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр инспекторлары тарафыннан башкарыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 2[1] өлеш өстәргә:

«2[1]. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт учреждениеләрендә һәм муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.».

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 пунктлары 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 27 апрель, № 19-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 95 статьяның 6 өлешендә:

а) 1 пунктта «зарарлы матдәләрнең» сүзләрен «пычраткыч матдәләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «зарарлы матдәләре» сүзләрен «пычраткыч матдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

2) 98 статьяда:

а) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Аеруча кыйммәтле су биологик ресурсларының яшәү тирәлеге, үрчү, уылдык чәчү, симертү урыннары, миграция юллары (күрсәткечләрнең берсе булганда) булган һәм (яисә) су биологик ресурсларының мондый төрләрен табу (тоту), аларны һәм аларның яшәү тирәлеген саклау өчен файдаланыла торган елганың, күлнең, сусаклагычның яр буе яклау полосасы киңлеге, ярның текәлегенә карамастан, ике йөз метр күләмендә билгеләнә.»;

б) 13 өлешнең 2 пунктына «, шулай ук территорияне балыкчылык өчен әһәмияткә ия булган су объектлары суларындагы иң чик мөмкин булган концентрацияләре билгеләнмәгән пычраткыч матдәләр белән пычрату» сүзләрен өстәргә;

3) 141 статьяның җиденче абзацында «зарарлы матдәләрне» сүзләрен «пычраткыч матдәләрне» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 27 апрель, № 20-ТРЗ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1[1] өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1[1]. Оешмалар салымның исәпләнгән суммасыннан 0,46 процент күләмендәге салымны 2011 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 1 гыйнварына кадәр эксплуатациягә кертелгән, техник документация буенча машина урыннары саны кимендә 100 берәмлек булган автомототранспорт чараларын куеп торуның күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларында) автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата, автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәтләре күрсәтү өчен әлеге куеп тору урыннарының (парковкаларның) гомуми мәйданының кимендә 70 процентын файдалану шарты үтәлсә, түли.»;

2) 2 өлештә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салымның исәпләнгән суммасыннан 4,55 процент күләмендәге салым түбәндәге рәвештә түләнә:»;

б) 1 пунктта:

беренче абзацта «сатып алынган мөлкәткә» сүзләрен «сатып алынган мөлкәткә карата» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

в) 8 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

г) 14 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

д) 15 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2[1] өлештә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2[1]. Салымның исәпләнгән суммасыннан 22,73 процент күләмендәге салым түбәндәге рәвештә түләнә:»;

б) 1 пунктта «җитештерүчеләрнең» сүзен «җитештерүчеләр тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) инновацияле проектларны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары нигезендә булдырылган технопарклар (индустриаль парклар), инновацияле-технологик үзәкләр тарафыннан – түләп вакытлыча хуҗа булуга һәм файдалануга яисә вакытлыча файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата;»;

г) 3 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

е) 5 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 27 апрель, № 21-ТРЗ

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 22 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяда:

а) 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыларның, дәүләт бюджет учреждениеләренең, автоном учреждениеләренең акчалата операцияләрен гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган казначылык счетларында чираттагы финанс елы башына тупланган калган акчалар, Татарстан Республикасы бурычы тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган Россия Федерациясе субъектларына кертелгәндә һәм Татарстан Республикасы бюджетында федераль бюджеттан бюджетара трансфертларның (субвенцияләрдән тыш) исәпләнгән өлеше соңгы өч хисап финанс елының икесе дәвамында Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәре күләменнән 20 процентыннан артмаганда. Бу чакта агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау өчен тотылган әлеге калган акчалар тиешле казначылык счетларында финанс елында торгызылырга тиеш.»;

б) 5 пунктның бишенче абзацында «әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә файдаланыла» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 26 статьяда:

а) 3 пунктның 4 пунктчасында «дәүләт гарантияләре буенча» сүзләрен «дәүләт гарантияләреннән барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның 4 пунктчасында «бәйдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча» сүзләрен «бәйдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләреннән барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктның 3 пунктчасында «бирелгән чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча» сүзләрен «бирелгән чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләреннән барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

3) 27 статьяда:

а) 3 пунктның 4 пунктчасында «муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «муниципаль гарантияләрдән барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3[1] пунктның 4 пунктчасында «бәйдерелгән муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «бәйдерелгән муниципаль гарантияләрдән барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3[2] пунктның 2 пунктчасында «бирелгән муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «бирелгән муниципаль гарантияләрдән барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга;

4) 38 статьяның 4 пунктында:

а) беренче абзацта «йөкләмәләр» сүзеннән соң «принципалның Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе белән тәэмин ителгән фактттагы йөкләмәләре суммасында, ләкин Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе суммасыннан артык булмаган күләмдә» сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта «йөкләмәләр» сүзеннән соң «принципалның муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән фактттагы йөкләмәләре суммасында, ләкин муниципаль гарантия суммасыннан артык булмаган күләмдә» сүзләрен өстәргә;

5) 43 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«федераль законнарда һәм (яисә) Россия Федерациясе Президенты указларында билгеләнгән очракларда Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды бюджеты субвенцияләре;»;

б) сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга.

2 статья

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 3 (I өлеш), «2 пунктчасыннан» сүзләреннән соң «, 31[12] статьясындагы 3 пунктының, 32[1] статьясындагы 3 пунктының» сүзләрен өстәп, «44[3] статьясындагы 3 пунктының» сүзләреннән соң «, 77 статьясындагы 5 пунктчасындагы икенче абзацның (Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен кимету өлешендә)» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

3 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 22 статьясындагы 3 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды күләмен чикләү өлешендә гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

4 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 26 статьясындагы 3 пунктының 4 пунктчасы, 4 пунктының 4 пунктчасы һәм 5 пунктының 3 пунктчасы, 27 статьясындагы 3 пунктының 4 пунктчасы, 3[1] пунктының 4 пунктчасы һәм 3[2] пунктының 2 пунктчасы һәм 38 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре (муниципаль гарантияләре) Татарстан Республикасы дәүләт бурычы (муниципаль бурыч) составында исәпкә алганда барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2022 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 27 апрель, № 22-ТРЗ

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясындагы 6[1] өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), «яисә аларны алмаштыра торган документларның булу-булмавын тикшерергә» сүзләрен «яисә мондый ярышларга керү хокукын бирә торган башка документларның булу-булмавын тикшерергә, шулай ук, Федераль законның 20 статьясындагы 2^2 өлешендә каралган очракларда, Федераль законның 20^5 статьясының 4 өлешендә каралган идентификация һәм аутентификация үткәрү тәртибен саклап, рәсми спорт ярышлары тамашачыларына, анда катнашучыларга, мондый ярышлар үткәрүгә җәлеп ителгән башка затларга аутентификация үткәрүне тикшерергә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 29 апрель, № 23-ТРЗ

Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы законнарын һәм норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын (алга таба – Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары), шулай ук норматив характерда булмаган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларын һәм аның Президиумы карарларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгели.

2 статья. **Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгаруга гомуми таләпләр**

1. Татарстан Республикасы территориясендә рәсми бастырып чыгарылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары гына кулланыла.

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актын рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналында беренче мәртәбә бастырып чыгару яисә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) йә «Рәсми хокукый мәгълүмат интернет порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче мәртәбә урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Интеграцияләнгән тулы текстлы хокукый мәгълүмат банкына (хокукый мәгълүматның эталон белешмәләр банкына) кертелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары текстлары шулай ук рәсми була.

3. Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары текстлары татар һәм рус телләрендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш, алар бер үк юридик көчкә ия була.

3 статья. **Татарстан Республикасы законнарын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе**

1. Татарстан Республикасы законнары аларны рәсми бастырып чыгару юлы белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан халыкка җиткерелә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы законы 14 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

3. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы законын имзалый һәм халыкка җиткерә йә күрсәтелгән законны кергән вакытыннан алып 14 календарь көн эчендә кире кага.

4. Татарстан Республикасы законы, әгәр федераль законда һәм (яисә) Татарстан Республикасы законының үзендә аның үз көченә керүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач Татарстан Республикасының барлык территориясендә бер үк вакытта үз көченә керә.

5. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарының үз көченә керү срогы аларның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә 10 көн тәшкил итәргә тиеш.

4 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе**

1. Норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары алар кабул ителгән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга тиеш. Норматив характерда булмаган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары өчен каралган тәртиптә һәм срокларда рәсми бастырып чыгарылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарлары, әгәр күрсәтелгән актларда аларның үз көченә керүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, кабул ителгән көненнән үз көченә керәләр.

3. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларының үз көченә керү срогы аларның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә 10 көн тәшкил итәргә тиеш.

5 статья. **Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе**

1. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары аларны чыгарган көннән соң 10 көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте башка органнарының дәүләт теркәвенә билгеләнгән тәртиптә алынган норматив хокукый актлары алар дәүләт теркәвенә алынган көннән соң 10 көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр һәм Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка белешмәләр кертелгән Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары яисә әлеге актларның аерым нигезләмәләре бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

4. Әлеге Закон белән регламентлаштырылмаган өлештә Татарстан Республикасы Президенты норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару тәртибенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

5. Әлеге Закон белән регламентлаштырылмаган өлештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару тәртибенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары, әгәр бу актларда аларның үз көченә керүнең башка тәртибе каралмаган булса, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керәләр.

7. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларының үз көченә керү срогы аларның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә 10 көн тәшкил итәргә тиеш.

6 статья. **Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бастырып чыгаруның һәм гомуми игътибарга җиткерүнең башка ысуллары**

1. Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы Президентының рәсми сайтында, ә Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары аларны кабул иткән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында әлеге законнарны һәм актларны рәсми бастырып чыгару өчен каралган срокларда урнаштырылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, әлеге Законның 2 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән басмалардан тыш, башка матбугат басмаларында да бастырып чыгарылырга, шулай ук гомуми игътибарга (халыкка) телевидение һәм радио аша җиткерелергә, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга, оешмаларга җибәрелергә, элемтә каналлары буенча тапшырылырга, машина тарафыннан укыла торган рәвештә таратылырга мөмкин.

7 статья. **Татарстан Республикасы законының, Татарстан Республикасы башка норматив хокукый актының рәсми бастырып чыгарганда күрсәтелә торган реквизитлары**

1. Татарстан Республикасы законын рәсми бастырып чыгарганда законның исеме, аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул итү датасы, аны имзалаган вазыйфаи зат, аны имзалау урыны һәм датасы, теркәү номеры күрсәтелә.

2. Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актын рәсми бастырып чыгарганда аның исеме, аны имзалаган вазыйфаи зат, аны кабул итү (чыгару) урыны һәм датасы, теркәү номеры күрсәтелә.

8 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарлары рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан җибәрелә.

2. «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, шулай ук башка актларны бастырып чыгару өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми басмасы булып тора. «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» структурасы, аны әзерләү, чыгару һәм тарату тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.

9 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11);

2) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына өстәмә кертү хакында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1);

3) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8);

4) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы икенче өлешенә үзгәреш кертү хакында» 2009 елның 29 июлендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2011 елның 30 июнендәге 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 11 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 4 (I өлеш);

7) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 17 июлендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7);

8) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2014 елның 11 апрелендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 4);

9) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 24 июлендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

10) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4, 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 25 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (IV өлеш);

11) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4, 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 сентябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш);

12) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 29 апрелендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 40 (I өлеш).

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2022 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 29 апрель, № 24-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 23 һәм 24 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 23 статьяда:

а) 4 өлешнең 4 пунктында «аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен премияләр» сүзләрен «премияләр, шул исәптән аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 8[1] өлеш өстәргә:

«8[1]. Әлеге Законда каралган дәүләт хезмәткәрләренә акчалата түләүне саклап калу һәм аларга акчалата компенсацияләр түләү очракларында дәүләт хезмәткәрләренә акчалата түләүне исәпләп чыгару Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезләмәләрен исәпкә алган Татарстан Республикасы Президенты указында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

2) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24 статья. **Дәүләт хезмәткәрләренә һәм дәүләт органы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды**

1. Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды һәм дәүләт хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фонды дәүләт хезмәткәрләренә һәм дәүләт органы хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондын тәшкил итә.

2. Дәүләт органнары дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондларын булдырганда әлеге Законның 23 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән түләүләрне башкару өчен акчалар карала.

3. Дәүләт органнары дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондлары әлеге Законның 23 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән түләүләрне финанс белән тәэмин итү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук түбәндәгеләрне финанс белән тәэмин итү өчен, булдырыла:

1) күләме Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә торган арттырылган акчалата түләүне аерым дәүләт органнарында түләүне;

2) федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында каралган башка түләүләрне.

4. Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү әлеге Законның 23 статьясындагы 13 өлеше нигезендә башкарыла торган дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды (фондның тиешле өлеше) дәүләт органы эшчәнлегенең эффективлыгы һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигезендә булдырыла.

5. Әлеге Законның 23 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән түләүләрне башкаруга җибәрелә торган акчалар суммасын билгеләү өчен вазыйфаи окладлар саны (бер елга исәпләгәндә) каралган дәүләт органнарының дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондларын булдыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

6. Дәүләт хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондларын булдыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 29 апрель, № 25-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданка З.Ф. Калоян шикаятенә бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацының, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2022 елның 8 апреле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацының, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка З.Ф. Калоян шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды. Докладчы судья Ф.С. Мусин мәгълүматын, яклар – гражданка З.Ф. Калоян, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенең юридик бүлеге башлыгы Р.Н. Сафин аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка З.Ф. Калоян Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган редакциясендә, 1.6 пунктындагы икенче абзацы, 2.7 һәм 2.8 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге Административ регламентның 1.6 пунктындагы икенче абзацы нигезендә гариза бирүче – яшәү урыны буенча Казан шәһәрендә теркәлгән, социаль наем шартнамәсе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләнең барлык әгъзаларының ризалыгы белән Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән район(-нар) администрациясенә мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданины.

Күрсәтелгән Административ регламентның 2.7 һәм 2.8 пунктлары Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеген тиешенчә билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче яшәү урыны буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясенә үзен аз керемле дип тану һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма югарыда күрсәтелгән районнар территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән булу сәбәпле, аңа мондый исәпкә алу өчен документларын кабул итүдән баш тартканнар.

Шуның белән бергә гражданка З.Ф. Калоян объектив сәбәпләр аркасында фактта үзе яши торган торак урында аның теркәлү мөмкинлеге булмавын билгеләп үтә.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – Торак кодексы) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) нигезендә яшәү урыны буенча теркәлү мәҗбүри булуы гражданны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу шарты булып тормый.

Гражданка З.Ф. Калоян раслаганча, аның яшәү урыны буенча теркәлү булмауга бәйле социаль наем шартнамәсе буенча торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә кую турындагы гаризасын кабул итүдән баш тарту югарыда күрсәтелгән Административ регламентның карала торган муниципаль хезмәт яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр булган очракта күрсәтелергә тиешлеген күз алдында тоткан дәгъва белдерелә торган нигезләмәләренә нигезләнгән. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче санаганча, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрне билгеләгән әлеге Административ регламентның 2.7 пункты һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрне беркетүче карала торган Административ регламентның 2.8 пункты гражданны торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә куюдан баш тарту мәсьәләсе җайга салынган Торак кодексының төп нормалары белән килешмиләр (54 статья), ә мондый исәпкә кую өчен мөрәҗәгать иткән гражданның гаризасын кабул итүдән баш тарту мөмкинлеге каралмаган.

Гражданка З.Ф. Калоян шикаяте Татарстан Республикасы Конституция судының 2020 елның 18 декабрендәге 41-О номерлы билгеләмәсе белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.6 пунктындагы икенче абзацының, 2.7 һәм 2.8 пунктларының конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алынган иде.

Эшне суд утырышында карый башлаганда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 2 февралендәге 330 номерлы карары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карарына үзгәрешләр кертелгән, алар нигезендә шикаять белдерелә торган Административ регламент яңа редакциядә бәян ителгән. Аерым алганда, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Административ регламентның элек 1.6 пунктының икенче абзацында, 2.7 һәм 2.8 пунктларында булган нигезләмәләре Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының (алга таба шулай ук – Административ регламент) 1.5 пунктындагы икенче абзацында, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларында үз чагылышларын тапкан. Шулай, Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацы гариза бирүче – Казан шәһәрендә яшәүче, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләнең барлык әгъзалары ризалыгы белән яшәү урыны буенча район(-нар) администрациясенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданины, дип билгели; Административ регламентның 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктлары Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт (алга таба шулай ук – муниципаль хезмәт) күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр исемлеген һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр исемлеген тиешенчә күздә тота.

Шуның белән бергә гражданка З.Ф. Калоян Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацы белән билгеләнгән хокукый җайга салу, кертелгән үзгәрешләргә карамастан, аны куллануның муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче үзенең яшәү урынын яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә раслау шарты белән гамәлгә ашырылу практикасын юкка чыгармый, дип күрсәтә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, китерелгән үзгәрешләр шулай ук тиешле гаризаны һәм кушымта итеп бирелгән документларны кабул итүне кире кагу өчен дә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен дә нигезләрнең тулы исемлеген билгели торган хокукый җайга салуның билгесезлеген юкка чыгармый.

Шуңа бәйле рәвештә суд утырышы барышында гражданка З.Ф. Калоян үз таләпләрен төгәлләштерде, алар нигезендә шикаятьтә бәян ителгән нигезләр буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацын, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше һәм аларга өстенлекләр бирелү тыела; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкаруда башка судлар яисә башка органнар компетенциясенә керә торган барлык очракларда фактларны тикшерүдән һәм аларны ачыклаудан тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп һәм хокук куллану практикасы белән бирелә торган мәгънәсен бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешендә генә карата карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

– Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктының икенче абзацы, анда муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче Казан шәһәрендә яшәүче граждан булуын билгели, күрсәтелгән нормага хокук куллану практикасы белән бирелә торган мәгънә буенча мөрәҗәгать итүченең Казан шәһәрендә яшәү факты аның яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә раслануга кайтып калуын күздә тоткан дәрәҗәдә;

– Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктлары, аларда беркетелгән нормаларны бәян итү рәвешләренең охшашлыгы гражданга муниципаль хезмәт күрсәтү нинди нигезләр буенча тукталырга мөмкин булуы турындагы мәсьәләдә билгесезлек тудырганга күрә.

2. Әлегрәк Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан кабул ителгән карарларда Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә карата нигезле чыгарылган карарлар (2020 елның 16 июлендәге 91-П номерлы һәм 2021 елның 2 мартындагы 96-П номерлы карарлар). Татарстан Республикасы Конституция судының карар чагылдырылган хокукый позициясеннән күренгәнчә, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзе федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләреннән гамәлгә ашырган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар нигезендә җирле үзидарә закон нигезендә һәм үз җаваплылыгы астында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә; җирле үзидарә органнары мөстәкыйль рәвештә муниципаль милекне идарә итә, җирле бюджетны төзи, раслый һәм үти, җирле салымнар һәм җыемнар билгели, җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыра, шулай ук җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итәләр.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясенең 7 һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Бу дәүләттә закон чыгару һәм башкарма хакимият органнарының гражданнар тарафыннан торакка хокукын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хокукый, оештыру һәм икътисадый шартлар тәэмин итү бурычы бар дигәнне аңлата.

Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданнарның торакка хокукын гамәлгә ашыру өчен үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак урыннарны яллау шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак урыннар бирәләр (3 пункт).

3.1. Торак кодексы гражданнарны социаль яллау шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпкә алып бару тәртибен билгеләүне торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертә (13 статьяның 7 пункты).

Әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе билгеләнгән.

Торак кодексы нигезендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге гражданнарның үз яшәү урыннары буенча күрсәтелгән органга тапшырылган яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән үзара хезмәттәшлек турында килешү буенча күпфункцияле үзәк аша тапшырылган гаризалар нигезендә гамәлгә ашырыла; законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гражданнар үзләренең яшәү урыннарыннан тыш та исәпкә алу турында гариза бирә алалар (52 статьяның 3 өлеше). 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлеше шундый ук нигезләмәләрне беркетә.

Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу муниципаль хезмәт булып тора һәм аны күрсәтү «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 12 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ регламент буенча гамәлгә ашырылырга тиеш. Шулай, Казан шәһәрендә гражданнарны мондый исәпкә алу әлеге эштә каралган Административ регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

Административ регламентның шикаять белдерелә торган 1.5 пункты гариза бирүче – Казан шәһәрендә яшәүче, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләнең барлык әгъзалары ризалыгы белән яшәү урыны буенча район(-нар) администрациясенә Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданины булуын билгели.

Дәгъва белдерелә торган норманың сүзгә-сүз эчтәлеген анализлаудан күренгәнчә, карала торган эшкә карата мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән муниципаль хезмәт алуга хокукын билгеләү өчен кирәкле шартлар исәбенә аның Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәве керә. Аталган нигезләмәне гамәлгә ашыру, хокук куллану практикасы күрсәткәнчә, мөрәҗәгать итүченең Казан шәһәрендә яшәү факты аның яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләргә туры килергә тиешлегенә кайтып кала.

Шикаять белдерелә торган норманың конституциячеллеген бәяләү «яшәү урыны» төшенчәсен ачыклаудан башка мөмкин түгел. Шулай итеп, Россия Федерациясе Конституциясенең 27 статьясы (1 өлеш) нигезендә Россия Федерациясе территориясендә законлы төстә яшәүче һәркем ирекле рәвештә күчеп йөрүгә, тору һәм яшәү урынын сайлап алуга хокуклы. Мәгънәсе буенча шундый ук нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 39 статьясында да бар.

Югарыда күрсәтелгән конституциячел нигезләмәләр Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясында һәм «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокуклы турында» 1993 елның 25 июнендәге 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) 2 һәм 3 статьяларында үсеш алган, аларда гражданның яшәү урыны буларак ул Россия Федерациясе законнары белән каралган нигезләрдә даими яки күпчелек рәвештә яши торган һәм яшәү урыны буенча теркәлгән торак урын билгеләнгән. Әлеге Россия Федерациясе Законының 2 статьясындагы 4 абзацы нигезендә Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны буенча теркәлүе Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны турында һәм аның әлеге яшәү урынында булуы хакында мәгълүматны теркәү исәбе органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәү булып тора. Шул ук вакытта 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 3 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Россия Федерациясе гражданнары тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе чикләрендә теркәлергә тиеш; теркәлү яисә аның булмавы гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары конституцияләрендә (уставларында) һәм законнарында каралган хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруны чикләргә нигез яисә аның шарты булып тора алмый.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән кертелгән Россия Федерациясе гражданнарын теркәү, аның конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча, хәбәр итү характерына ия булган һәм гражданның тору яки яшәү урыны буенча булу фактын чагылдыра торган Россия Федерациясе чикләрендә гражданнарны исәпкә алуның федераль законда каралган ысулы гына булып тора; теркәү исәбе органнары гражданның тору һәм яшәү урынын сайлаганда ирекле ихтыяр белдерү актын расларга гына вәкаләтле; нәкъ менә шуңа күрә теркәү исәбе рөхсәт характерында була алмый һәм гражданның тору һәм яшәү урынын сайлау конституциячел хокукын чикләүгә китерергә тиеш түгел (1995 елның 24 ноябрендәге 14-П номерлы, 1996 елның 4 апрелендәге 9-П номерлы, 1998 елның 15 гыйнварындагы 2-П номерлы, 1998 елның 2 февралендәге 4-П номерлы, 2021 елның 30 июнендәге 31-П номерлы һ.б. карарлар).

Россия Федерациясе Югары Суды шулай ук үзенең хокук куллану практикасында игътибарны шуңа юнәлдергән: Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясы һәм 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 2 һәм 3 статьялары эчтәлегеннән теркәлүнең «яшәү урыны» төшенчәсенә туры килмәве һәм үзеннән-үзе гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясендә, Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясе составындагы республикаларның конституцияләре һәм законнарында каралган хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру шарты булып тора алмавы аңлашыла (Россия Федерациясе Югары Суды Президиумы тарафыннан 2016 елның 20 декабрендә расланган Россия Федерациясе Югары Судының суд практикасына күзәтүенең (№ 4, 2016) IV бүлегендәге 12 пункты).

Гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар дип тану тәртибен регламентлаштыруга карата Россия Федерациясе Конституция Суды шулай ук түбәндәгеләрне билгеләп үтә: хокуктан явыз ният белән файдалануны булдырмау максатларында закон чыгаручы норматив хокукый актларда аерым оештыру-исәпкә алу кагыйдәләрен күздә тота ала; гражданның яшәү урыны буенча теркәлүе булуы турында шартны кертү – чөнки ул торакны гадел бүлүне тәэмин итүгә, торак шартларын яхшырту буенча исәпкә кую турында гариза белән мөрәҗәгать итүче гражданнар һәм муниципаль торак белән идарә итү органнары ягыннан мөмкин булган явыз ният белән файдалануны булдырмый калуга, шулай ук торак фонды милекчеләренең, башка гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән – Россия Федерациясе Конституциясенең 17, 19, 27 һәм 40 статьялары күрсәтмәләре белән туры килми торган буларак карала алмый; шул ук вакытта гражданның яшәү урыны, гомуми юрисдикция суды тарафыннан теркәү төре белән мәҗбүри бәйле булмаган юридик фактлар нигезендә билгеләнергә мөмкин (2011 елның 30 июнендәге 13-П номерлы Карар; 2000 елның 13 июлендәге 185-О номерлы, 2000 елның 5 октябрендәге 199-О номерлы, 2002 елның 9 апрелендәге 123-О номерлы билгеләмәләр).

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә кую өчен кирәкле шарт буларак, яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән бергәттән, гражданның үзе тарафыннан тапшырылган тиешле суд карары белән расланган булырга мөмкин. Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацында кулланылган «яшәүче» төшенчәсе «яшәү урыны» төшенчәсен билгели торган граждан һәрвакытта да яшәү урыны буенча фактта үзе яши торган торак урында теркәлмәгән булырга мөмкинлеген күз алдында тоткан югарыда китерелгән конституциячел күрсәтмәләр һәм граждан законнары нигезләмәләре призмасы аша хокук куллану практикасында аңлашылырга һәм кулланылырга тиеш.

Мондый алым анда булган норматив нигезләмәләрнең, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нигезләрен һәм тәртибен, димәк аларны куллану практикасын да ачыклый торган нигезләмәләрнең мәгънәсен аңлатып, Административ регламентның нигезен тәшкил итәргә тиеш.

Шуның белән Татарстан Республикасы Конституция суды Административ регламентның 1.5 пунктының икенче абзацы, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче Казан шәһәрендә яшәүче граждан булуын билгеләп, үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле шарт булып әлеге муниципаль берәмлек территориясендә яшәү факты ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән расланырга тиеш булган яисә аны тапшыру бурычы гражданга йөкләнергә тиеш булган тиешле суд карары белән расланырга тиеш булуын күздә тоткан дәрәҗәдә һәм шикаять белдерелә торган норманың Казан шәһәрендә мөрәҗәгать итүченең яшәү фактын бары тик яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә раслануга кайтып кала торган мондый кулланылышына юл куймый дип саный һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү механизмын әлеге муниципаль хезмәтне алуга дәгъва кылучы граждан тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенә, гражданның Казан шәһәре территориясендә яшәү фактын раслаучы суд карарын тапшыру мөмкинлеген күрсәтеп, үзгәрешләр кертү юлы белән камилләштерүгә комачауламый. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституция суды Административ регламент нормаларына, шул исәптән гражданны һәм аның гаиләсен торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында гариза формасын раслаучы Административ регламентның 3 кушымтасына төгәллекләр кертү максатка ярашлы дип саный, аның эчтәлегеннән аңлашылганча, «яшәү урыны» төшенчәсен аңлау ул бары тик яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә расланырга мөмкин булуына кайтып кала. Бу Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацын һәм, димәк, аның белән системалы бердәмлектә булган Административ регламентның башка нормаларын куллануга бертөрле якын килүне тәэмин итәр иде.

3.2. Торак кодексының 54 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алудан баш тарту турында җирле үзидарә органнары тарафыннан карар чыгару өчен нигезләр исемлеге беркетелгән. Әлеге Кодексның 52 статьясындагы 4 өлешендә каралган гражданның торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын раслаучы документлар, исәпкә алуны гамәлгә ашыручы орган тарафыннан ведомствоара мөрәҗәгатьләр нигезендә алына торган документлардан тыш, мөрәҗәгать итүченең үзе тарафыннан тапшырылмаган очракта мондый баш тарту мөмкин була (1 пункт); әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың ведомствоара мөрәҗәгатькә җавабы Торак кодексының 52 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавын раслый, моңа мондый соратып алына торган документ яисә мәгълүматның югарыда күрсәтелгән органнар яисә оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын раслаган очраклар керми (1.1 пункт); тиешле гражданнарның торак урыннарга мохтаҗлар исәбендә тору хокукын расламый торган документлар тапшырылганда (2 пункт); граждан торак урынына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын алу нияте белән гамәлләр кылган көннән биш ел вакыт узмаган булса (3 пункт). Шундый ук нигезләмәләр 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 1 өлешендә беркетелгән.

Торак кодексының әлеге нормалары система барлыкка китерүче булып торалар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу мәсьәләләрен алга таба җайга салу өчен гомуми параметрлар билгелиләр. Гражданнарны мондый исәпкә алу, үз чиратында, 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарга хезмәт күрсәтү процедурасын Торак кодексында, шул исәптән аның 54 статьясында билгеләнгән хокукый җайга салудан килеп чыга торган фикер йөртү чикләрендә төгәлләштерергә һәм структуралаштырырга тиешле административ регламентлар кысаларында күрсәтелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүдән гыйбарәт. Торак кодексының әлеге статьясын дәвам итеп һәм, муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпне күздә тоткан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының һәм 14 статьясының 1 өлешендәге 7 һәм 8 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре таләпләрен үтәү йөзеннән, әлеге эштә карала торган Административ регламент белән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу (документларны асылы буенча карап тикшермичә кире кайтару) өчен нигезләрнең (2.7.1 пункт) һәм әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләрнең (2.8.2 пункт) тулы исемлеге билгеләнгән.

Административ регламентның 2.7.1 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага бирү (1 пунктча); муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза формасында булган мәҗбүри тутырылырга тиешле юлларны тулысынча тутырмау (дөрес итеп тутырмау, хаталы итеп тутыру) (2 пунктча); документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру (3 пунктча); муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка тапшырылган документларның (шәхесне таныклый торган документ; муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ) гамәлдән чыккан булуы (4 пунктча); тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, текстта Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган бозып язулар һәм төзәтүләр, аларның эчтәлеген төгәл аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар булу (5 пунктча); муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон формада биргәндә билгеләнгән таләпләрне үтәмәү (6 пунктча); электрон формада тапшырылган документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен бирелә торган документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар булу (7 пунктча); гаризаны гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклау вәкаләте булмаган зат бирү (8 пунктча).

Административ регламентның 2.8.2 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен түбәндәге очраклар нигез булып тора: гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины булып тормый (әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса) (1 пунктча); әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз теләге белән тапшырылмаган булса, дәүләт органының, җирле үзидарә органының, оешманың ведомствоара мөрәҗәгатькә җавабы гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавын таныклый (мондый органнар яисә оешмалар карамагында әлеге соратып алына торган документ яисә мәгълүмат булмау тиешле гражданнарның торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын раслый торган очраклардан тыш) (2 пунктча); 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә гражданинны аз керемле дип тану өчен нигезләр булмау (3 пунктча); гражданнарның торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын расламаган документлар тапшырылган һәм (яисә) мөрәҗәгать буенча алынган (4 пунктча); гражданнар тарафыннан аларны торак урыннарга мохтаҗ дип танырга мөмкинлек биргән гамәлләр кылынганнан соң, законнарда билгеләнгән вакыт узмаган (5 пунктча); гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган яки тапшырылган гаризада һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар (6 пунктча).

Административ регламентның дәгъва белдерелә торган 2.8.2 пунктының сүзгә-сүз эчтәлеген анализлау күрсәткәнчә, анда билгеләнгән хокукый нормалар үзләренең хокукый мәгънәсе буенча федераль һәм республика законнары нигезендә билгеләнгән логикага җавап бирәләр һәм гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алыну хокукын гамәлгә ашыруда нигезсез чикләүләрне беркетмиләр. Шул ук вакытта аталган хокукый җайга салуга Административ регламентның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеген беркетүче 2.7.1 пункты нигезләмәләре билгесезлек кертә, чөнки анда беркетелгән нигезләмәләрнең эчтәлеген анализлаудан күренгәнчә, граждан тарафыннан тапшырыла торган документларның анда билгеләнгән бәяләү критерийлары, асылда, гражданның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак аны исәпкә куюда хокуклылыгын билгеләү максатларында кулланыла торган мондый исәпкә куелудан баш тарту турында карар кабул итү стадиясендә гамәлгә ашырыла торган бәяләү критерийлары белән охшаш.

Административ регламентның 2.7.1 пунктына хокук куллану практикасы белән бирелә торган мәгънәсе муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен аның тарафыннан билгеләнгән нигезләрнең исемлеген киңәйтеп аңлатуны рөхсәт итә һәм фактта асылы буенча бирелгән документларны кабул итү стадиясендә бәяләүгә китерә, бу асылда алдан тикшерү булып тора, аның нәтиҗәләре буенча документларны кабул итү кире кагылырга мөмкин. Шул ук вакытта мондый җайга салу Торак кодексының 54 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләре һәм аның белән үзара бәйле мондый бәяләү гражданнарны торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә куюны кире кагу турында карар кабул итү стадиясендә, ягъни гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны асылы буенча караганда булырга мөмкинлеген күздә тоткан 52 статьясындагы 4 өлеше нигезләмәләре белән каршылыкка керә.

Шуның белән бергә Административ регламентның 2.7.1 пунктының конституциячеллеген бәяләү аталган регламентның 2.7 пунктына мөрәҗәгать итмичә мөмкин түгел, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу һәм документларны асылы буенча карап тикшермичә кире кайтару арасында мәгънәдәшлек бар. Бу күрсәтелгән документларны кабул итү процедурасы мөрәҗәгать итүченең шәхесен һәм вәкаләтләрен билгеләүгә, гаризасын тиешенчә рәсмиләштерү күзлегеннән чыгып тикшерүгә, тапшырылган документларны гаризага кушымталар итеп күрсәтелгән документлар белән чагыштыруга һәм аларның җиңел укылышына йогынты ясый торган, аларның дөрес булмавы ихтималын тудыра торган техник зарарлануларны тикшерүгә кайтып калырга тиеш дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Административ регламентның дәгъва белдерелә торган 2.7.1 пунктының нәкъ менә шундый хокукый мәгънәсе гражданны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куюда аның хокуклылыгын билгеләү һәм, димәк, тәкъдим ителгән документларны асылы буенча карау бары тик гражданны исәпкә алу (исәпкә алуны кире кагу) турында карар кабул иткәндә генә мөмкин, бу Административ регламент нормалары системасында алдан тикшерү үткәрүне билгели торган – документларны асылы буенча бәяләүгә юл куймый торган формаль билгеләр буенча документларны карауны билгеләгән нигезләмәләрне беркетү кирәклеген нигезләүне күз алдында тоткан Торак кодексының 52 статьясындагы 4 өлешенең һәм 54 статьясындагы 1 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләренең турыдан-туры гамәле белән алдан билгеләнгән. Шикаять белдерелә торган норманы аңлауда һәм аңлатуда бары тик мондый алым гына җирле үзидарә органнарының гражданнар белән конструктив бәйләнешен тулысынча тәэмин итәчәк, гариза биргәндә граждан тарафыннан җибәрелгән асылда техник хаталар (җитешсезлекләр) тиешле исәпкә куюны кире кагуга китерергә мөмкин булган хәлләрне юкка чыгарачак, шулай ук гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү процессы сузылуны булдырмый калачак.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Административ регламентның 2.7.1 пунктында каралган җайга салу, анда беркетелгән нигезләмәләрне бәян итү формасы күзлегеннән, югарыда күрсәтелгән әлеге норманың максатчан билгеләнешен төрле мәгънәдә аңлауны һәм муниципаль хезмәт алганда гражданнарның хокукларын акланмаган чикләүне бетерү максатларында үзгәртелергә тиешлегенә басым ясарга кирәк дип саный.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларында билгеләнгән хокукый җайга салу, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуның оештыру-процедура механизмы элементы буларак, торак законнарының махсус нормаларында салынган төп принципларны эзлекле рәвештә гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацын, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацының әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе һәркем өчен мәҗбүри, бу аның хокук куллану практикасында теләсә нинди башкача аңлатылуына юл калдырмый.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм

2.8.2 пунктларын, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларының әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе һәркем өчен мәҗбүри, бу аларны хокук куллану практикасында теләсә нинди башкача аңлатуга юл калдырмый.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 105-П
Татарстан Республикасы Конституция суды

29 апрель – Халыкара бию көне

ӨЕРМӘ

Мондый истәлекле көннең барлыгын ишетсә, мөгаен, һәр татар кешесе, «канатлы» биюче Рудольф Нуриевны искә төшерер. Үзем дә, аның язмышындагы кара яки ак тапларны барлыйсы килеп, кулыма кабат язучы Равил Вәлинең «Шөһрәт» китабын алдым. «Узган гасырның алтмышынчы еллар башында мәшһүр биюләре белән үзен һәм татар халкын дөньякүләм таныткан Рудольф Нуриевның (1938–1993) шөһрәтле исеме күпме вакытлар тыелуда ятканнан соң, кабат туган иленә әйләнеп кайтты», – дип яза ул сүз башында.

Дәлил

Биюченең чит илдә калырга теләве күп кенә матбугат чараларында «ул ирекле булып яшәргә теләде», «ул шулай уйлаган» дигән җөмләләр белән аңлатыла. Әмма биюче, бәлки теләге искиткеч көчле булса да, бу адымга әзер булганмы икән? Нәрсә дисәң дә, чит илгә беренче чыгуы бит. Күп еллардан соң укучысына туган иленә кайтырга мөмкинлек биргән укытучысы Александр Пушкин дәлилләре дә башкача уйларга мөмкинлек бирә.

«…Ул гаҗәеп саллы дәлил, үз сәгате җиткәнне көтеп, күн тышлы кара чемодан эчендә ятә. Теге чакта Франциянең Ле Бурже аэропортында хуҗасыннан аерылып Лондонга киткән (нәкъ шунда Нуриевны Парижлагы гастрольләрдән соң Лондонга оча торган самолетка утыртмыйлар, туган иленә китәчәк, 7 елга төрмәгә утырту турында карар чыгару өчен беркетмә төзелгән була инде), ул чемодан исән-сау гына Ленинград каласына кайтып җитә һәм, биюченең яраткан остазы буларак, Пушкин кулына тапшырыла. Хатыны белән ачып карасалар, исләре китә. Анда «Мәхәббәт турында легенда» балетындагы Фәрхад ролен бию өчен тегелергә тиешле киемнәргә дип сатып алынган яшел хәтфә тукыма ята. Ленинградның Киров театрында бу спектакльдә катнашу Рудольфның күптәнге хыялы була. Бу бит – Нуриев чит ил гастрольләреннән туган иленә, нәкъ менә Ленинградка исән-сау гына әйләнеп кайтырга җыенган дигән сүз, дип нәтиҗә ясый остаз һәм моның дөреслегенә башкаларны да ышандыра ала».

Биюченең җиде елга ирегеннән мәхрүм итү өчен карар чыгарырга нигез була алган беркетмә кайдан килеп чыккан? Күп кенә чыганакларда «иленә хыянәт иткән өчен», «чит илдә калган өчен» дигән аңлатмалар күренә. Югыйсә бу беркетмә Франциядә, Рудольф гастрольләрдә йөргәндә үк язылган бит. Коллективтан аерылып урамнарга чыгып йөрсә дә, үҗәтлегенә ирек бирсә дә, бу әле җинаять тә, хыянәт тә түгел.

Көнчелек

Чәчрәп торган үҗәт холыклы булганга, яшь биюче көтмәгәндә тәртәгә тибеп куйган гамәлләре белән дошманнарын гел арттыра бара. Аеруча атаклы Киров театры сәхнәсендә тоташтан утыз ел биеп, инде тәмам азу ярган баш балетмейстер Константин Сергеев көнчелеген яшерә алмый. Аның хатыны Дудинская «Лауренсия» балетында төп рольне көтмәгәндә-уйламаганда дәрт-дәрманы ташып торган Рудольф белән биергә була. Бу хәл моңарчы төп рольләрне беркемгә дә биергә теләмәгән ирне чыгырдан чыгара. Көчле алкышлар белән барган балетның икенче көнендә үк кара көеп йөри башлый. Икенче яшьлеген кичергән хатынының көнләшүе, әллә инде дөньяның иң оста балероны булырга дәгъва кылган Нуриевны? Бәлки, икесе дә сәбәп булгандыр. Алар арасында иҗади бәхәсләр дә килеп чыга. Ил һәм дөнья тарихында Рудольф беренче мәртәбә аяк бармаклары очында бии башларга теләк белдергәч, баш балетмейстерның гаҗәпләнүенә чик-чама булмый. «Без совет сәхнәсендә ир-ат биючеләр йөзен кызарта, хәттә ки аларны мыскыл итә торган хәрәкәтләрне башкаруга юл куймабыз», – ди.

Әлбәттә инде, Рудольфны чит илләргә гастрольләргә алырга да теләмиләр. Мең бәлә белән исемлеккә кереп, килеп җиткәч, бер атна сәхнәгә чыгармый интектерәләр. Сергеев барлык алкышларның Нуриевка буласыннан бик курка. Тәртәгә тибеп маташкан егетне урынына кертү юлын гастроль башлыгы урынбасары дип саналган КГБ офицеры белән күптән уйлап куя. Ник булмаган үзеннән бик та көнләшкән хезмәттәше, юаш-күндәм Юрий Соловьев белән бергә кертәләр. Шулай итеп, Рудольфның һәр сүзе, минуты-секунды белән дигәндәй, тиешле кешеләренә җиткерелеп барыла. Соңрак Юрийны тагын да нәтиҗәлерәк итеп файдаланырга кирәк дигән фикергә киләләр. Үзләре әйткәнчә, Нуриевның төлке койрыгы «зәңгәр» капкынга элэктерү өчен, төнлә белән Соловьев, биле авыртып торудан зарланып, массаж ясап алуын үтенергә тиеш була. Аннан инде ике шаһит алып кереп, беркетмә төзергә генә кала. Бу документ нигезендә аны илгә кайткач та җиде елга хөкем итәргә була. Шуны да әйтеп үтик: Нуриев башлап биегән рольләрне башкарып, СССРның халык артисты булуга ирешкән Соловьев 1977 елны, нибары 36 яшендә, үз дачасындагы ау мылтыгыннан атылып үлә. Бу фаҗигага юлыгуның Рудольф язмышына бәйләнешле рухи газаплары да тәэсир итми калмагандыр дип фаразлана.

Сикереш

Париждагы илчелеккә хат-фәрман юлланганнан соң, тамашачыларның ярсуыннан куркып, Нуриевка Франциядә гастрольләрен тәмамларга ирек бирергә, ә менә Англиягә алып бармаска, дигән карарга киләләр. Мәкерле план төзелә. Инде самолетка керер вакыт җиткәч, Сергеев аны артистлар чиратыннан тартып чыгара. «Сез безнең белән очмыйсыз», – дигән хәбәрне җиткерә. Имеш, Никита Хрущев аның тиз генә кайтып җитүен һәм Кремль банкетында биюен көтә. Аннан безгә Мәскәүдән килеп кушылырсыз, дип тә өсти. Иптәшләре исә, саубуллашканда, кайгыны уртаклашабыз, Руди, дип биючене шаккатыралар. Аларга, әнисе авырып киткән, дип әйтелгән була. Озатырга килгән француз дуслары хәлне тиз аңлап ала. Бу килеш Мәскәүгә кайтып китү турында сүз дә булырга мөмкин түгел – җиде елга төрмәгә ябылып, иҗади хыялларыңның котылгысыз төстә җимерелеп төшүе дигән сүз бит бу. Димәк, бары бер юл кала… Рудольфның дусты Клара Сент, биюченең ризалыгын алып, бу хакта полиция хезмәткәрләренә җиткерә. Кызга, ул үзе безнең янга килеп, сыену урыны сорап мөрәҗәгать итәргә тиеш, диләр. Әмма бу мөмкин хәл булмый, Рудольфны ике яктан ике әзмәвер җитәкләгән. Полиция хезмәткәрләре исә алардан ун метр ераклыкта гына кафе янында басып тора. Клара хәйләгә керешә, сакчылар бер мизгелгә кулларын ычкындырганны сизми дә калалар. «Рудольф тирән сулыш ала да, йон эрләүче әбиләр кулындагы орчык кебек бер урында бөтерелеп, өскә томырыла. Соң чиккәчә киерелеп туйган аяклар исә нәкъ зыр-зыр әйләнгән вертолет канатларын хәтерләтә. Башы аэропорт залының түшәменә тия язгач, антраша алымын кулланып, Рудольф кафе-бар турысында дирижабль кебек очып бара башлый. Кабриоль алымын кулланып, галәмәт көчле аякларын бер-берсенә бәргәләп куярга да онытмый. Очар кошларның канат кагуына охшаган бу гаҗәеп хәрәкәтләрне ул очыш ераклыгын озынайту өчен эшли. Һәм үз дигәненә ирешә…» Аны, сайлау мөмкинлеге биреп, 15 минутка полиция бүлмәсендәге ике якка алып чыга торган ике ишек арасында калдыралар. Монда да ул озак уйлана әле…



✓ Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында ел саен Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале уза.
✓ Уфада Башкортстан дәүләт опера һәм балет театрында ел саен Рудольф Нуриев исемендәге халыкара балет фестивале уза.
✓ 2017 елда Казанның Идел буе районындагы Примавера бистәсендәге урамга аның исеме бирелде.
✓ 2018 елда Казанда Дзержинский урамында һәйкәл куелды.
✓ 2018 елда Бөекбритания актеры һәм режиссеры Рэйф Файнс биюче турында «Ак карга» дигән фильм төшерә.
✓ Россиядә «Рудольф Нуриев. Гыйсъянчы демон» дип аталган фильм төшерелә.

Хыял

Туу турындагы таныклыгына Рудольф Нуриевның дөньяга килгән урыны итеп Иркутскидан ерак түгел «Раздольная» исемле тимер юл станциясен язып куялар. Поездда туа ул. Әнисе Фәридәнең өч бала белән Хәсән күле янында японнар белән бәрелештә булган офицер ире Хәмит янына барышы була. Тиздән гаиләне Мәскәүгә җибәрәләр. Әмма сугышның тагын да хәтәррәге башлана. Әтисе фронтка китә. Әнисе дүрт бала белән башта Чиләбе өлкәсенә, аннан иренең туган җиренә – Уфага юл тота. Шунда яшәп калалар.

…Үзсүзле һәм горур холыклы әтисе бердәнбер улының биюче булам дигән теләгенә каршы төшә. 12–14 яшьлек балалар янына Рудольф унҗидесен тутыргач кына килә ала. Беренче зур җиңү аңа 1958 елның апрелендә килә. Бөтен илнең иң сәләтле биючеләре һәр яз саен Мәскәүдә үткәрелә торган үзенчәлекле ярышка җыела. Алар арасында Казанда Рудольф Нуриев та була һәм җиңү яулый. Беренче урынны алды дию генә аз була аның өчен, егет совет сәхнәсендә искиткеч яңалыклары белән ярсу өермә булып күтәрелә.

…Балет сәнгатендә моңарчы күрелмәгән дәртле биюләре белән Рудольф Нуриев башта Париж, Дания, аннары Лондон тамашачылары күңелен дә бик тиз яулап ала.

Кайту

Барыннан да элек Рудольф әти-әнисе, туганнары белән очраша алмаудан интегеп яши. Җидееллык төрмәгә ябылу куркынычы гел баш өстендә үткен кылыч кебек эленеп торганлыктан, ул Уфага кайтып килү турында хыяллана да алмый. Ә туганнарына чит илгә чыгу өчен виза бирми аптыраталар. Үзгәреш елларында кайчандыр туган илләреннән китәргә мәҗбүр ителгәннәр кабат үз ватаннарына кайтырга рөхсәт ала. Әмма биюче бөтенләйгә кайтып китү турында уйламый. Нәрсә дисәң дә, иң авыр көннәрдә Франция аны үз куенына сыендыра, дөньякүләм биеклеккә менәргә булышып, Париж операсындагы бик мәртәбәле җитәкчелек дилбегәсен ышанып тапшыралар. Бу ышанычны да акларга кирәк. Әмма бу хәбәр аңа рәхәтлек бирә. Нәкъ шул көннәрдә Уфадагы апасы шалтырата. Әнисен паралич суккан. Табиблар, озак яши алмас, диләр. Рудольф, бар дөньясын онытып, егерме алты ел күрмәгән әнисе янына ашкына. Аңа нибары ике тәүлек вакыт бирәләр. Үлем чигендәге әнисенең хәрәкәтсез калган, ләкин әле җылы кулларыннан тотып, Рудольф шактый озак утыра. Сеңлесе белән, кар ерып, әтисенең каберен зиярәт кылып кайта. Шуның белән санаулы минутлар үтеп тә китә.

Тагын бер тапкыр кайта биюче туган илгә. Аны өметле дирижер сыйфатында башта Казанга, аннан Ялта белән Питер каласына репетицияләр үткәрергә чакыралар. Татар иленә – әнисенең кендек каны тамган җиргә килә алу аның иң татлы һәм якты хыялы була. Килгәндә үк машинадан төшеп, Татар бистәсендә әнисе белән әтисе беренче тапкыр очрашкан урыннан бер уч туфрак ала ул. Иртәгесен репетицияләр үткәрә. Хәле бик авырайса да, план буенча эшен тәмамларга уйлап, Питер каласына юнәлә. Тик авыру чигенми. Аны дуслары тиз арада Парижга алып кайтып китәләр. Юлда алынган анализлар Рудольфның пневмония белән генә түгел, ә перикардит, ягъни йөрәк тышчасының көчле ялкынсынуын да күрсәтә. Бу чир иммунитет дефициты синдромы булган авыруларда еш очрый һәм, гадәттә, үлемгә китерә…

Туган илдән ерагта яшәсә дә, канатлы биюче үз халкына мәңгелек мирас калдырды. Ул – төрле кыйтгалар һәм бар җиһан сәхнәләрендә татар дигән горур исемне дөньякүләм биеклеккә алып менү һәм таныта алу.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм аның законлы мәнфәгатьләренең төп гарантияләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләрен Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә Россия Федерациясе законнары белән кертелгән вәкаләтләр чикләрендә җайга сала.

2. Татарстан Республикасы территориясендә балаларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон) билгеләнгән төшенчәләр кулланыла.

3 статья. **Бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә законнар белән җайга салу;

2) бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне тикшереп тору;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасының дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне, әлеге бәяләүнең критерийларын да кертеп, үткәрү тәртибен, мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен билгеләү;

3) мөстәкыйль туризмны гамәлгә ашыру кысаларында балалар катнашында туристлар төркемнәре үтү өчен һәм балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмаларында булган балаларның оешкан төркемнәре үтү өчен тәкъдим ителә торган туристлар маршрутлары (хәрәкәтләнүнең башка маршрутлары) исемлеген эшләү һәм раслау өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү, аны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

4) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

4 статья. **Баланы аның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан, пропагандадан һәм агитациядән яклау**

Баланы аның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан, пропагандадан һәм агитациядән, шул исәптән милли, сыйнфый, социаль түзеп тора алмаучанлыктан, алкоголь продукциясе һәм тәмәке әйберләре рекламасыннан, социаль, раса, милли һәм дини тигезсезлек пропагандасыннан, порнография характерындагы мәгълүматтан, традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый торган мәгълүматтан, шулай ук көч куллануны һәм рәхимсезлекне, наркоманияне, токсикоманияне, үз-үзләрен тотышларын җәмгыятькә каршы куюны пропагандалый торган басма продукция, аудио- һәм видеопродукция таралудан яклау Федераль закон һәм «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Балалар өчен социаль инфраструктура булдырганда бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә балалар өчен социаль инфраструктура объектларын төзү нормативларын исәпкә ала. Күрсәтелгән нормативлар Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә һәм, әгәр Татарстан Республикасы законнарында башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы үзенчәлекләрен, Татарстан Республикасы халыклары традицияләрен исәпкә алып кулланыла.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү балаларның тормыш эшчәнлеген, аларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балалардагы авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең уңай бәяләмәсе нигезендә рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасының дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне, әлеге бәяләүнең критерийларын да кертеп, үткәрү тәртибе, мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт милке булып торган, балалар өчен социаль инфраструктура объектларына караган һәм төзелүе, аерымлануы яисә сатып алынуы балаларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны тәэмин итү, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт (җир кишәрлекләре, биналар, корылмалар һәм төзелмәләр, җиһаз һәм башка мөлкәт) әлеге максатларда гына кулланыла ала.

Татарстан Республикасының дәүләт милке булып торган һәм балаларга белем бирү, аларны үстерү, аларның ялы һәм аларны савыктыру, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә кулланыла.

4. Әгәр балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы яисә муниципаль оешма үзенә беркетелгән милек объектларын арендага бирсә, түләүсез файдалануга тапшырса, арендага бирү шартнамәсен һәм түләүсез файдалану шартнамәсен төзү алдыннан гамәлгә куючы тарафыннан әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән тәртиптә балаларның тормыш эшчәнлеген, аларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны, аларга медицина ярдәме күрсәтүне һәм балалардагы авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мондый шартнамәләр төзүнең нәтиҗәләрен бәяләү үткәрелергә тиеш.

Арендага бирү шартнамәсе һәм түләүсез файдалану шартнамәсе, аларны төзү нәтиҗәләренә үткәрелгән бәяләү нәтиҗәсендә әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән шартларның начарлануы мөмкинлеге билгеләнсә, төзелә алмый.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән шартнамәләр төзү нәтиҗәләренә бәяләү үткәрү турында таләп Федераль законның 13 статьясындагы 4 пунктының өченче абзацында каралган дәүләт яисә муниципаль һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы белән шартнамәләр төзү очракларына кагылмый.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 29 апрель, № 26-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2[1] статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешнең 1 пунктында:

а) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) дүртенче абзацта «һәм өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылган эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарга» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3[1] өлешнең беренче абзацында «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм дәүләт программасына кертелергә тиешле эш бирүчеләрне сайлап алу критерийларын исәпкә алып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3[3] өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3[3]. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләргә хокуклы:

1) эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен авыл җирлегенә күченүче эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә финанс ярдәме билгеләргә;

2) өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны, Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан дәвам итәргә теләүче эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарны һөнәри укытуны яисә аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру тәртибен билгеләргә;

3) өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга, Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан дәвам итәргә теләүче эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарга, эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан һөнәри уку узу яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җиргә җибәрелгәндә, финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шулай ук күрсәтелгән финанс ярдәменең күләмнәрен билгеләргә;

4) эш белән тәэмин ителмәгән күпбалалы ата-аналарның, инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарның балаларны тәрбияләү бурычларын хезмәт эшчәнлеге белән бергә алып баруы өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны эшләргә һәм гамәлгә ашырырга.»;

4) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 29 апрель, № 27-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 21 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«4. Балигъ булмаганнарга, аларга медицина ярдәме күрсәтелгәндә, Федераль законның 37 статьясындагы 14[1] өлеше нигезендә балаларга медицина ярдәме күрсәтү стандартларына, клиник рекомендацияләргә кертелгән һәм дару препаратының аны куллану инструкциясендә бәян ителмәгән күрсәтмәләре (характеристикалары) нигезендә кулланыла торган дару препаратлары билгеләнергә мөмкин.

5. Вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән авырулар яисә халәтләр (авырулар яисә халәтләр төркемнәре) исемлегенә кертелгән авырулардан яисә халәтләрдән (авырулар яисә халәтләр төркемнәреннән) интегүче затлар, балигъ булу яшенә җиткәннән соң, егерме бер яшь тулганчы, аларга мондый авырулардан яисә халәтләрдән (авырулар яисә халәтләр төркемнәреннән) балигъ булу яшенә җиткәнче медицина ярдәме күрсәткән медицина оешмасында күренергә һәм дәвалануны дәвам итәргә хокуклы.».

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 29 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 29 апрель, № 28-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен тыл хезмәтчәне **Аникин** Николай Степанович, Бөек Ватан сугышында катнашучы **Гаврилов** Генрих Данилович, тыл хезмәтчәне **Феоктистова** Антонина Ильинична, Бөек Ватан сугышында катнашучы **Чирвон** Петр Анисимович; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен тыл хезмәтчәне **Галимова** Руза Исмәгыйль кызы, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Дунаев** Николай Иванович, хезмәт ветераны **Зиннуров** Ильяс Авзал улы, хезмәт ветераны **Маланьина** Людмила Васильевна, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Матбугат хезмәте җитәкчесе **Макуева** Резида Галимҗан кызы, хезмәт ветераны **Салихов** Харис Салих улы, хезмәт ветераны **Сөләйманов** Тәлгать Мирзаһит улы, «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесенең музей фондларын саклаучысы **Такташ** Рәмзия Идиятулла кызы, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Минзәлә-информ» филиалы баш мөхәррире – җитәкчесе **Шаһиев** Илдус Ильяз улы, хезмәт ветераны **Шәйдуллин** Тимур Галимулла улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың икътисади потенциалын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан» агросәнәгать паркы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Власов** Олег Геннадьевич; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Алан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Габделвәлиев** Айрат Фәләх улы; республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Кара Алтын предприятиесе» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Насыйбуллин** Марат Галимулла улы; эшләрендә уңышларга ирешүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Ресурс-Холдинг» ягулык-энергетика ассоциациясе генераль директоры **Мостафин** Рушад Фәндүс улы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Боровое Матюшино комплексы әйдәүче белгече **Нәбиуллина** Венера Геннадьевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең концерт бүлеге вокалчы артисты (солисты) **Асаев** Рөстәм Мәҗит улына; «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле вокалчы артисты (солисты) **Шәрәпова** Гөлшат Фоат кызына; «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе драма артисты **Голубев** Марат Викторовичка; «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Латыйпова** Зөлфия Наил кызына; «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе драма артисты **Ряшина** Елена Юрьевнага **«Татарстан Республикасының халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Акматова** Динара Абдулабәк кызына; «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Яндаев** Александр Петровичка; «Татарстан Республикасы Дәүләт академик симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең валторначылар төркеме концертмейстеры **Антонов** Сергей Владимировичка; «Татарстан Республикасы Дәүләт академик симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең кларнетчылар төркеме оркестр артисты **Гыйльманшин** Фәгыйль Мансур улына; Чаллы шәһәренең «Орган залы» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе артисты – концерт башкаручысы (барлык жанрларны) **Сөләйманова** Илсөяр Таһир кызына; «ЭЛВИН ГРЕЙ» МУЗЫКАЛЬ ЛЕЙБЛЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте вокалчы артисты (солисты) **Юлъякшин** Радик Мөхәрләм улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Дивана

Кешеләр арасында ахмаклык ни өчен алама сыйфат булып чутланадыр – аңлап та, аңлатып та булмый. Югыйсә әйбәт нәрсә бит инде ул. Менә мин адәм баласының ахмаклыгына сокланып туя алмыйм. Үзеңнең ахмаклыгың да көләсене китереп, җанга җылы бирел тора инде ул. Тормышка бик җитди карамасаң, әлбәттә. Ә тормыш ул җитдилекне яратмый, чөнки үзе – даһи юморист, һәр мизгелеңне адәм көлкесе итәргә генә тора. Ләкин балаларның ахмаклыгы аеруча кызык. Әгәр ул үзеңнеке белән бергә үрелсә, бигрәк тә.

Бакча карау чоры бит инде. Мин дә бәрәңге бакчасына беркадәр карап тордым да, «на всякий случай» дип, тырмалап чыгарга булдым. Дөрес эшләгәнмен, бераз чүбе чыкты. Аны капчыкка салабыз да махсус урынга илтеп ташлыйбыз инде. Монда әллә ни күп түгел, шунда баручы берәрсенең арбасына салып җибәрсәң дә була. Җыеп капчыкка тутыру – өч минутлык эш. Шулай гына итәргә кирәк иде. Ләкин шул ахмаклык...

Юк, үзеңнеке булгач, аны бик ахмаклык дип әйтәсе дә килми икән. Сагыш бугай бу. Менә элек басуларда салам яндыра торган идек бит инде. Бөтен тирә-якка тәмле булып төтен исе тарала иде. Бу бары тик язда гына була торган күренеш, үзенә күрә яз хәбәрчесе, көннәр җылыны билгесе сыман иде. Янындагы сыйныфташ кызларның игътибарын яуларга тырышып, ут аша да сикереп чыгасың иде. Алар, синең батырлыкны күреп: «Яратам сине генә!» – дип мөнньма асылынмый инде, «Дивана», – дип елмаеп кына куя. Ә «дивана» яратам дигәнне аңлата. Кем уйлап тапкандыр инде, уй каты шулай дигән булалар иде. Без шиша идек. Ә кызлар әйтә иде. Ул сүз яратуны аңлатмаса да, кызларның йөзендәге елмаю әллә нинди сантыйлыкларга дәртләндерә иде. Ә сантыйлык белән батырлык арасы әллә ни ерак түгел. Кичкә кадәр шулай йөреп, кара сөремгә күмелеп, өенә кайтып керәсең, көязегә күз салсаң, әллә нинди эшләр майтарган әкият батыры кебек тоеласың. Авылдагы бакчаларда да бәрәңге чүбен җыеп яндырыш иде. Кич җитүгәрәк ут төртеп җибәрәсең, ул ялкынланып бераз яна да кузга әйләнеп, җемелдәп тора. Күрше кызлары да бакчаларына чыга, син шул яхка үрелеп-үрелеп күз саласың. Борынга ис кергән вакыт бит инде... Җирдә – кузлар, күктә – йолдызлар, күршедә – кызлар... Бөтен авылга төтен тарала. Аның тәмле исе танауларны кытыклата. И, рәхәт иде шундый... Яз бит ул... Яшьлек бит ул!

Хәзер алай ук түгел ул. Янгыннан куркалар. Элек авылда бер мичкә су тутырып йөрүче бер пожар аты бар иде. Хәзер ике пожар машинасы. Хәбәр булса, выжт итеп, күрше авыллардан да килеп җитәләр. Элек берәү дә янгыннан курыкмый иде. Хәзер дер калтырап торалар. Шуңа бәрәңге сабакларын яндырырга кушмыйлар инде, штраф та салалар бугай, чүплеккә илтеп түгәләр. Тик миндәге ахмаклыкның яшь чаклардагы рәхәтлеке кире кайтарасы килде. Өч минутта капчыкларга тәяп куясы теге чүпкә ут төртеп җибәрдем.

Кич иде, тыныч, җил-фәләннең әсәре дә юк. Җил дә тере җан иседер инде ул. Авылга тәмле төтен исе таралган вакытларны ул да сагынадыр. Мин ут төртеп җибәрү белән, абзар почмагына качып күзәтеп торган шикелле, җил дә килеп чыкты. Учак янында ләззәтләнеп бераз тын торды да сызгырып та җибәрде: «Фью-фью-фью!..» Башта ындыр артына карап исте, аннан акрын гына борылып, авыл ягына төтен таратырга тотынды. Мин белгәннәремне укый-укый ни кылырга аптырап торган арада, бөтенләй дәртләнеп исә башлады. Ялкын күтәрелде, кузлар очарга тотынды. Мин су сиптеру өчен шланганы көйләп өлгергәнче, учакны абзар ягына таратырга тотынды. Абзар әллә ни ерак түгел, анда мал юк, әмма тавыклар астына салырлык кына коры салам-печән бар.

Учак урынын суга батырдым. Җил аны киткән кузлар эзен дә коры калдырмадым. Кузы абзарга төшмәде микән, дигән шик калды инде барыбер. Берничә минут янгын чыкканын көтеп абзар тирәли йөрдем дә, «на всякий случай» дип, абзарны да суга манчыдым. Баштанаяк коендырып чыктым. Янгын чыкмасын дип шикләнсәң, бөтен нәрсә күз булып күренә икән. Мин шуларның барысын да берәм-берәм чылаттым. Ярты көн шулай үзды.

Янгын чыкмады. Өч минутлык эш өчен әллә күпме вакытны әрәм итсәм дә, күңелдә үкенү юк. Сагынган инде мин барыбер авылның шау-гөр килеп торган вакытларын. Язлардагы салам яндырган, бакчаларда бәрәңге сабагыннан учак яккан чакларны сагынам. Ул сагышлар җанда дөрләсә дә, авыл өстенә төтене таралмый. Бары тик ягымлыланып калган җил белән әллә кайдан килгән назлы елмаюлы тавыш кына ишетелеп китә: «Дивана...» Ә «дивана» «яратам» дигәнне аңлата...

И, сокланган инде бу адәм баласы. И, рәхәт инде бу ахмаклыкның татлы мизгелләре...

Внимание
СТРОИТЕЛИ
Выполняем все виды работ

Хозблок, веранды, пристройки, заборы, сараи, кровля крыш, сайдинг, бани, фундаменты, дачные дома. Выравнивание домов. Работаем с вашим или своим материалом.
Телефон: 8 965 848 02 60 Станислав
Реклама

Газетаның киләсе саны 6 майда чыга

ТӨРЕК КЫЗЫ ГАМЗӘ НУР НАЛБАНТ:

«ТАТАРЧАНЫ ЯТЛАП ТҮГЕЛ, ҖЫРЛАП ӨЙРӘНДЕМ»

Татарчаны дүрт айда өйрәнгән Гамзә Нур Налбант башкаларны да Тукай теленә өйрәтергә җыена. Төркиянең Искешәһәр каласындагы Османгази университеты магистры Гамзә быел татар теле һәм әдәбиятыннан IX Халыкара олимпиаданың гран-при иясе булып танылган иде. 24 яшьлек төрек кызына татар теле нигә кирәк?

tatarstan.ru

:: Гамзә, татар теле сине кайсы ягы белән гашыйк итте?

– Татар теле ул – үзе мәхәббәт. Җыр, шигырь кебек. Аңа хәзинәләр яшеренгән. Бик борынгы сүзләр кулланасыз. Төрки халыкта сакланмаса да, татар телендә яши. Минемчә, татар теле төрки халыкларның уртак теле булырга тиеш.

:: Безнең телебез турында шулкадәр яратып, тәмләп сөйлисең. Аны өйрәнү кыен булмадымы?

– Мәктәптә укыган чакта ук татарча җырлар тыңлап, телегезгә гашыйк булдым. Истанбул университетында төрек теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча белем алдым. Без иске төрки телләрне өйрәндек. Бер ел Казахстанда укыдым. Шуның өчен казах телен бик әйбәт беләм. Анда да татарлар белән таныштым. Төркиягә кайтканда, «Гамзә, син хәзер казах телен беләсең, татарча өйрән», – дип максат куйдым. Интернеттан татар кызлары Зәйнәп, Зилә, Айсылу белән дуслашып, аралаша башладым. Көн саен сөйләшергә, җырларыбызны тыңларга тырыштым. Соңыннан челтәрдән барлык татарча киноларны карадым. Бер дә авыр булмады. Татар теле – йөрәгемдә. Казан мине һаман үзенә тартып тора. Анда бер генә тапкыр булсам да, инде яшәрга телим. Татарстанга сәяхәт исә онытылмаслык булды.

:: Көнгә ничә сүз ятлый идең?

– Мин ятламадым, җырлар, подкастлар тыңладым. Татар телен без өйрәнгән иске төрки сүзләр, казахча һәм төрекчә белән чагыштырдым. Һәм шуның өчен бик тиз өйрәндем. Бик кечкенә бер сүзлек тә бар иде, ләкин ул гына җитми бит. Мин татарлар белән сөйләштем. Аңламаган сүзләрне алардан сорадым. Татар дусларым почта аша татарча китаплар җибәрде. Аның да файдасы тиде.

:: Төркия татарлары белән аралашасыңмы?

– Мин үземә яшәр өчен татарлар иң күп булган Искешәһәрне сайладым. Монда татар авыллары бик күп. Кырым һәм Казан татарлары яши. Ләкин, кызганыч, мондагы татарлар туган телен белмиләр. Белгәннәр белән татарча сөйләшәбез. Искешәһәрдә татар мохите бар. Сабантуй да уздыралар.

:: Гаиләң татар телен өйрәнүгә ничек карый?

– Әниемә дә татарча өйрәтәм. Төрки халыкларның ризыкларын пешерергә яратам. Үзбәк самсасы, уйгыр лагманы, бавырсак, мантый... Җырларыгызны да бергә тыңлыйбыз.

:: Казанга кученеп килү теләгем дә бар, дидең...

– Бу – минем иң зур хыялым. Анда укырга, яшәргә телим. Сез тарих белән бергә яшисез, Казан бик матур шәһәр. Татарча сөйләшергә яратам. Хәзер рус телен дә өйрәнәм.

:: Туган телне ничек саклап була? Татар телен белмәучеләргә ни әйтер идең?

– Аны буыннан-буынга тапшыру – бөтенебезнең дә вазыйфасы. Гаиләдә туган телдә сөйләшергә кирәк дип уйлыйм. Әти-әниләр үз мәдәниятләренең матурлыгын өйрәтергә тиеш. Үз каһарманнарын, үз бизәкләрен, ризыкларын өйрәнгән бала теле белән дә горурланачак. Ничек тәрбия бирәсең, бала шулай үсә. Башка телләрне дә өйрән, ләкин иң беренче урында туган тел булырга тиеш. Башка телдә уйлаучылар шул телнең вәкиле булып санала, минемчә. Бу хәл Германиядә дә еш очрый. Анда төрекләр бик күп яши. Алар арасында төрекчә белмәгәннәр дә бар, немец телен төрекчәдән яхшы белгәннәр дә бар, төрекчә акцент белән сөйләшүчеләр дә бар. Немец телен дә өйрәнсеннәр, башкасын да белсеннәр. Татарлар да русчаны, инглизчәне өйрәнсен. Төрекчәдә «Bir dil – bir insan» дигән мәкаль бар. Бер тел – бер кеше дигән сүз бу. Ягьни бер тел өйрәнсәң, син дөньяда – бер, икене белсәң, ике кеше белән.

:: Телне мәктәпләрдә балаларга кызык итеп өйрәтергә кирәк, диләр...

– Телне балаларга уен аша өйрәтү кызык. Мин хәзер чит ил кешеләренә төрек телен өйрәтәм. Казахстанда да укыттым. Ольгаларга ияреп, алты яшьлек рус малае да килгән иде. Бер үзенчәлеге бар: динозаврлар турында сөйләгәндә генә мине тыңлый. Башка темага игътибар итми. Мин аның өчен тактага, дәфтәргә, бөтен җиргә динозавр рәсемнәре ясый идем. Бер генә түгел, төрле алымнар белән телне өйрәтергә кирәк дип уйлыйм. Балага нәрсә кызык, шуны белергә кирәк.

:: Үз проектларың бармы?

– Әйе, бар. Ел саен төрки халыклардан 6–7 баланы бушка укытам. Яхшы укучылар да бар. Узган елда төрекчәне уйгур студентларына онлайн укыткан идем, быел татар балаларын өйрәтәм. Казах, татар телен өйрәт әле, дип килүчеләр дә юк түгел.

:: Тыныч төннәр, Гамзә! *(Без аның белән телефон аша аралаштык.)*

– Тыныч түгел шул төнем. Казанда «Без татарча сөйләшәбез» акциясе уза. Дусларым чарадан кызыклы видеолар җибәрә. Күңелем белән Казанда мин.

Сәрия МИФТАХОВА

ӘБИ БӘХЕТЕ – КИЯҮДӘН

Менә шундый кеше

Роза Ихсановага багышлап кияве махсус җыр башкара хәтта. Нинди була икән ул «алтын теща» дип әйтерлек хатын-кыз? Буаның Югары Наратбаш авылына баргач, таныштык без Роза ханым белән. 71 яшендә булса да, әле дә авыл кибетендә сатучы булып эшли ул.

– Эти иртә үлеп китте. Ул чакта 38 яшьлек әнием 4 бала белән тол калды. Иң зурыбызга – 15, кечебезгә 7 яшь иде. Әнигә гел ярдәм итә идек. Сигез яшемдә басуда чөгендер эшкәртә идем инде мин. Эштән курыкмадым. Гомерем буе эш аты булдым, – ди Роза апа. – Ирем зур таяныч булды. Беркайчан да ирләр эшен эшләтмәде. Без Фиргатем белән бер класста укыдык. Бер партада утырдык. Озаклаганый бергә яшәвебезгә 50 ел була иде.

Кечкенәдән бер-берләрен белгәч, гаилә корып җибәрү авыр булмаган. Өстәвенә Роза апаның каенатасы да, каенанасы да бик тә акыллы, дини, тәрбияле кешеләр булган. Гаиләдә хөрмәткә урын зур булган. Әнә шул сыйфатларны әти-әниләрдән – балаларга, алардан оныкларга күчерергә тырышалар. Дүрт балаларын да кооператив техникумда укыта Ихсановлар. Диләсе белән Гүзәле әниләре төсле Казанда белем ала, игезәкләре Рамил белән Рамиләсе Буада укып кайта.

– Балаларымның тормышы өчен сөенеп туя алмыйм. Атлаган саен шөкер кылам. Киявләрем дә, киленнем дә үзебезгә охшап килде. Өч кияүне дә уларын кебек күрәм. Кайтып керүгә, үзләре белеп эшкә тотыналар. Моны эшләгез, тегене эшләгез, дип аптыратмыйм. Әмма кияүләр әллә кайдан эш табалар. Киленемне дә ял иттерергә тырышам, – ди Роза апа. – Мине ник яратлар дисеңме? Киракмәгән җиргә кысылмаганга. Әгәр кызларым ирләре белән сүзгә килә икән, мин аларны ишетмим. Шуңа кияүләр яраталар да инде. Кызларга да, ирне

ир итәргә кирәк, дип кенә торам. Алар матур торса, безгә рәхәт.

Роза апа үзе дә, кызлары да бик яшь күренәләр. Аларга үз яшьләрен биреп булмый. Сере нидә соң? Баксаң, бар да гади икән. Роза апа әйтүенчә, кешедән көнләшмичә, гайбәт сөйләмичә, тормышка шатланып яшәсәң, картаймыйсың! Ә оныклар белән бөтенләй яшәреп бетәсең! Ихсановлар, оныклар өчен дип, сыерны да бетермиләр икән. Җәйгә оныкларның дүртесе кайта дип көтәләр. Бөтенесе бергә җыелганда, 19 кеше булалар икән. Инде кызлары Дилә белән кияүләре Наил үзләре әби-бабай булган.

– Күңелем кин, өемдә урын җитәрлек. Кешеләрне яраттым. Бер сөйләшеп утырыга ни җитә?! Авылыбызның бетүен теләмим. Төннәр буе күңел белән урам буйлап йөрим. Буш йортларны саныйм. Кибет бетсә, авыл бетә, шуңа эшне ташламыйм. Кешегә бик кирәк товарларны кайтартып сатам, – ди ул. – Сатучы булмасам, җырчы булыр идем. Җырларга бик яратам. Мине кечкенәдән концертларда җырлатып йөрттеләр. Балаларым кайтса, тормышыбыз бәйрәмгә әйләнә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Май ялларында нишлисез?

Килешәсездер: бу көннәрдә иң актуаль сорау бу. Ике кеше очрашса, берсе барыбер шул сорауны бирә. Ни дисәң дә, май бәйрәмнәре – элек-электән көтеп алына торган бәйрәмнәрнең берсе.

Инде кышкы каникул тәмамлануга ук май ялларын көтә башлаучылар бар. Каланыкылар ял, табигать кочагына чыгу турында уйланса, саланыкылар бу ялларга күмәкләшеп башкара торган эшләрен планлаштырып куя. Дөресен әйткәндә, инде аны планлаштырасы да юк: һәр гаиләнең бу көннәрдә эшли торган үз эшләре, инде гадәткә әйләнгән эш графигы була. Без үзебез, мәсәлән, гомер-гомергә 30 апрель көнне бәрәңге чыгара, ә 1 май көнне өй юа идек. Һәм ел саен диярлек бу көнне яңгыр ява иде. Әле күршеләр: «Бүген болар өй юмыйдыр, яңгыр яумый», – дип көлешә һәм бу хак та була иде. Дөрес, соңгы елларда бу гадәт үзгәрде. Хәзер өй юу күпкә җиңеләйде, аны күмәкләшеп башкара торган эшләр исемлегеннән төшереп калдырдык лабаса.

Эш димәктән, үз каралтысы белән яшәгән, эшлим дигән кешегә анысы ел әйләнәсе бетми, көндәлек табылып тора. Әмма көнә әйбәт булса, май яллары ул бакчада эшләү, чистарту, бәяу, агарту ише эшләргә тәгаенләнә. Кемнәрдер зиратларга барып, якыннарының каберлекләрен тәртипли, кемдер тузган капка-коймасын яки каралты-курасының бер өлеше яңартуга тотына...

– Дөресен әйткәндә, быел бөтен эш бергә өелергә охшый, кайсыннан башларга да белгән юк әле. Бәрәңге дә чыгарылмаган, агачлар да агартылмаган. Җир кибеп, кояш чыкса, бу эшләр бер-бер артлы, тиз-тиз эшләнә инде анысы. Язгы көн озын бит ул. Бер тотынганчы гына куркытып тора, эшли башлагач, берние юк. «Май ялларында нишлисез?» – дигән сорау бирсәк, авыл кешесенең күбесе шулай җавап бирер иде, мөгаен.

– Башкалар кебек без дә үз бакчабызда, каралты-курада эшлибез, тәртиплибез дә, аннан, бер көнне, көн матур булса, бергәләп табигатькә чыгып, иркенләп ял итәбез. Башкалардан үзгә ниндидер аерым бер гадәтебез юк, – диюче дә табылыр. «Бу ялларда барыбыз да гаиләләребез белән төп нигезгә җыелабыз. Һәр елны бергәләп эшли торган эшләр табыла. Быел да инде әти-әнинең планлаштырылган эшләре бар» яки «Яллар күп булгач, рәхәт, әби-бабайларга, туганнарга барып булышырга, хәл белешергә дә, үзебезнең өйләрдә эшләргә дә вакыт кала», – диючеләр дә булыр.

Кешегә май ялларында нәрсәдер эшлә дип әйтәсе-кисәтәсе юк, көне генә кояшлы, матур булсын, кешеләр үзләре үк бу ялларны көтеп ала бит...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 262

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+